ПИОНЕР КАЛӘМЕ



ЯНВАРЬ 1940 № 1

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!
ЛЕНИН—СТАЛИН ЭШЕ ӨЧЕН КӨРӘШКӘ ХӘЗЕР БУЛ!

ПИОНЕР КАЛӘМЕ

БАЛАЛАР ӨЧЕН ЧЫГАРЫЛА ТОРГАН АЙЛЫК ӘДӘБИ ЖУРНАЛ. ВЛКСМ НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ҺӘМ МӘГАРИФ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ ОРГАНЫ.

БУ НОМЕРДА:

Гадилек (иптәш Сталинның 1924 ел, 28 январьдә Кремль курсантлары кичәсендә сөйләгән речення) 2
Бөтен дөньяны балкыта ленинизм нурлары (татар халык җырларыннан) . . . 3
Син мәңгелек (Мөршидә Вильданова шигыре) . . . 4
Ленин (Гали Галеев шигыре) . . . 4
Ленин ничек укыган . . . 5
Малай (язып алучы С. Мирер) . . . 7
СССР Верховный Советы Президиумы указы . . . 8
Ленин эшен бөек дәвам иттерүче иптәш Сталинга (ВКП(б) Үзәк Комитеты котлавы) 9
Иптәш И. В. Сталинга (ВЛКСМ Үзәк Комитеты котлавы) . . . 11
Рәхмәт белдерү (Сталин) . . . 12
Скульптор (С. Хәким шигыре) . . . 12
Яңа ел (Г. Латыйп шигыре) . . . 12
9 нчы январь (М. Горькийнең шул исемдәге әсәреннән өзек) . . . 13
В. В. Куйбышев турында истәлекләр (Елена Куйбышева) . . . 17
Буяучы абый (Ж. Тәржеманов шигыре) . . . 22
Ванька (А. П. Чехов хикәясе) . . . 23
Россияне уятучы көчле набат (мәкалә) . . . 26
Бишек җыры (Фәез Хәбибуллин шигыре) . . . 27
Арктика батырлары (мәкалә) . . . 28
Онтылмас комедия авторы (А. Әхмәт мәкаләсе) . . . 31
Катокта (Н. Хәмидуллин һәм В. Гобәйдуллин шигырьләре) . . . 32
Күңелле ял . . . ;
Рәсемнәр.
Журналның тышлыгында: „Чаңгыда“. Художник А. Б. Полуев рәсме.

Редакциянең адресы: Казан шәһәре, Бауман урамы, 19.
Матбугат йорты (2 нче кат, 5 нче бүлмә). Телефон № 18—78.

ЯНВАРЬ 1940 № 1



ГАДИЛЕК

(Иптәш Сталинның 1924 ел, 28 январендә Кремль курсантлары кичәсендә сөйләгән речендән)

Ленин белән мин беренче тапкыр 1905 нче елның декабрендә, большевикларның Таммерфорста (Финляндиядә) булган конференциясендә очраштым. Мин партиябезнең тау бөркетен, олы кешене, политик яктан гына түгел, бәлки әгәр дә теләсәгез, гәүдә ягыннан да олы кешене күрергә өмет иткән идем, чөнки минем хыялымда Ленин сынлы һәм мәһабәт бер великан төсендә сурәтләнә иде. Гади кешеләрдән һич нәрсә белән, бөтенләй бер нәрсәсе белән дә аерылмый торган, уртачадан тәбәнәгрәк буйлы, иң гади бер кешене күргәч инде минем күңелсезләнүем никадәр зур булды...

Гадәт булып киткән ки, җыелыш членнары „олы кешенең“ килеп керүен тын да алмыйча көтсеннәр өчен, ул гадәттә җыелышларга соңгарак калып килергә тиеш, шуның белән бергә, олы кешенең килеп күренүе алдыннан җыелыш членнары: „тсс... әкрен... ул килә“ дип искә төшерәләр. Бу җолачылык миңа артык нәрсә түгел төсле күренә иде, чөнки ул уңышлы тәэсир итә, хөрмәт тудыра. Лениннең җыелышка делегатлардан иртәрәк килүен һәм кайдадыр бер почмакка кысылып, гади кешеләрчә әңгәмә алып баруын, конференциянең иң гади делегатлары белән иң гади әңгәмә алып баруын күргәч, минем күңелсезләнүем бик зур булды. Яшермим, ул чакта бу миңа кайбер зарур кагыйдәләрне берникадәр бозу булып күренде.

Лениннең бу простойлыгын һәм гадилеген мин тик соңыннан гына аңладым, аның күзгә чалынмый калырга омтылуы яки, һәр хәлдә, күзгә бәрелмәскә һәм үзенең югары дәрәҗәсен сызып күрсәтмәскә омтылуы,—менә бу сыйфат, яңа массаларның, кешелек дөньясының иң тирән „түбән катлауларының“ простой һәм гади массаларының яңа юлбашчысы булган Лениннең иң көчле якларыннан берсе булып тора.

Бөтен дөньяны балкыта ленинизм нурлары

(Татар халык җырларыннан)

Биек тауларның башында
Күренә чуен юллары,
Бөтен дөньяны балкыта
Ленинизм нурлары.

Иптәш Ленин, тыныч йокла,
Мавзолееӊ эчендә,
Көрәшергә әйткән сүзеӊ
Һәммәбезнеӊ исендә.

Иртә торып тышка чыксам,
Кошлар кунган тирәккә,
Иптәш Ленин үзе үлсә дә
Исме калды йөрәктә.

Зур, зур шәһәрләр салына
Эшчеләр кулы белән,
Безне Сталин җитәкли
Лениннеӊ юлы белән!



Рәсемдә: В. И. Ленин портреты. Кызыл армеец иптәш Федарин эше. (Түбәндә) Кокушкино авылында комсомолецлар-колхозниклар Ленин йорты-музеендә.

СИН МӘҢГЕЛЕК

Тәрәзәдән үрлеп тышка карыйм,
Бураны уйный январь аеның,
Бураны уйный — минем йөрәгемнең,
Чикләре юк һич тә кайгымның.

Урамнарда йөрим, җил сызгыра,
Битне үбә январь салкыны.
Өйгә керсәм — миндә дөрләп яна
Югалтуның тиңсез ялкыны.

Без югалттык, даһи Ильич сине,
Югалткандай җирнең кояшын,
Мондый авыр, иң зур югалтуны
Күрмәде әле кешелек дөньясы.

Син мәңгелек кояш, син сүнмәдең,
Ирек бирдең безгә, нур сиптең,
Коллык богауларын өзеп ташлап
Бәхетле иттең илне, гөл иттең.

Сине сөйгән җылы караш белән
Сталинны сөя илебез.
Сез, даһилар, биргән бәхет өчен
Кайнар рәхмәт сезгә сөйлибез.

Көрәштәшең безне тәрбияли,
Бакчасында карап үстерә,
Зур көрәшләр өчен чыныктыра
Һәм иркәли белә, үз күрә.

Ильич Ленин, Иосиф Сталинның
Акылы төзде яңа дөньяны —
Совет илен, диңгез уртасында
Магрур басып торган кыяны.

Мөршидә Вильданова.

Ленин

Ленин!
Ленин—
Көрәш кырларында
Җиңүләргә илткән жырыбыз,
Кешелекнең бөек баһадиры,
Йөрәгебез һәм күз нурыбыз.

Кара еллар аша иң беренче
Кояш булып җирдә балкыдың,
Нурлар итеп даһи акылың һәм
Йөрәгеңнең сүнмәс ялкынын.

Патшалыкта газап чиккән халык
Синнән көчләр алып йөрәккә,
Курку белмәс корыч сафлар булып,
Күтәрелде кискен көрәшкә.

Ташып аккан Нева елгасыдай
Ташкын купты илнең өстендә,
Актарылды таулар,
Тетрәде җир,
Күк күкрәде халык көченнән!

Ленин!
Ленин—
Канлы көрәшләрдә
Җиңүләргә илткән җырыбыз,
Килер гасырларның байрагы син,
Йөрәгебез һәм күз нурыбыз.

Егерме беренче январь көнне илдә
Хәрәкәт сүнде, тынлык урнашты.
Ал байраклар түбән иелделәр,
Зур кайгыдан тамды күз яше.

Шул көн аның якын көрәштәше
Кремльнең якты залында,
Ал чәчәкләр белән уратылган
Бөек Ильич табуты янында
Ул ант бирде:
Синең байракларны
Күз карасы кебек сакларга,
Синең туры юлдан батырларча,
Җиңә-җиңә алга атларга.

Ленин!
Ленин!
Ленин, тыныч йокла!
Онытмабыз һич тә без сине,
Бар халыклар саклап алып бара
Байракларга язып исмеңне.

Сталиныбыз синең юлың белән
Алып менде безне югары,
Менгән саен якынрак булып
Балкый коммунизм кырлары.

Мул уңышлы колхоз кырлары һәм
Шахталар һәм фабрик-заводлар,
Шушы җырны йөрәгендә йөртә
Илебездәге барлык халыклар:

„Сталин китерде бу көннәргә
Данлы еллар аша үткәреп,
Ленин сүзен дошманнарга каршы
Үткен кылыч итеп күтәреп!“

Гали Галиев.

Кукмара.

Ленин ничек укыган

Владимир Ильичнең сөеклe сеңлесе, Мария Ильинична Ульянова, үзенең истәлекләрендә Ленинның укырга бик нык яратуы турында яза. Ильич бөтен гомере буена укырга яратты.

— Ул бик яш вакытта ук, гимназиянең өлкән классларында укыганда (Владимир Ильич гимназияне 17 яштә тәмамлады), төннәр буена китаплар укый иде... Ул китапларны укый гына түгел, аларны конспектлар төзеп, күчермәләр ясап, бик яхшылап өйрәнә һәм үзләштерә белә иде... Библиотекага бару өчен ул сөргендә дә, чит илләрдә дә һәрбер буш вакыттан, һәрбер буш сәгаттән файдаланды. Владимир Ильич үз гомерендә белемнең төрле тармаклары буенча гаять күп китап укыды. Бездә аның бик күп дәфтәрләре һәм күчермәләре саклана. Болар аның күпме һәм ничек укыганын бик ачык күрсәтеп торалар.



Укый белү—зур сәнгат ул. Ленин бу сәнгаткә тулысынча ия иде. Ленин укыган бик күп китаплар Маркс-Энгельс-Ленин институтының корыч шкафларында саклана. Бу китапларда күп төрле билгеләр, сызыклар бар. Ленин кулында һәр вакыт карандаш яки ручка тотканы хәлдә укыган. Китапның читенә билгеләр һәм сызыклар ясау белән ул үз хәтеренә булышлык иткән.

Надежда Константиновна болай дип яза:

— Ленин, үзенең хәтере бик гүзәл булуына да карамастан, аңа гына ышанып калмады. Ул фактларны хәтердән генә, „чамалап" кына бер кайчан да әйтеп бирмәде. Ул аларны бик зур төгәллек белән әйтеп бирә торган иде. Ул тау-тау материаллар карады (ул бик тиз укый һәм шулай ук бик тиз яза да иде) һәм хәтерендә калырга тиешле нәрсәләрне язып барды. Аның дәфтәрләрендә китаплардан язып алынган күп кенә өземтәләр, күчермәләр саклана. Бер вакыт ул минем „Үз-үзлегеңнән белем алуны оештыру" исемле брошюрамны карады. Мин анда, иң кирәклеләрен генә язып алырга кирәк, дигән идем. Ленин минем бу карашымның дөрес булмавын әйтте,—аның тәҗрибәсе башкача. Язылганнарны ул соңыннан берничә тапкыр укып чыга иде. Аның тарафыннан төрле билгеләр, сызыклар ясалу һ. б. әнә шул турыда сөйлиләр.

Әгәр дә китап Ильичнең үзенеке булса, ул аның читенә билгеләр ясый һәм китапның тышлыгына бит номерларын язып куя, билгеләнгән урынның әһәмиятенә карап, сүзләрнең астына бер яки ике сызык сыза...

Үз эше өчен аеруча әһәмиятле булган китапларны Ленин кат-кат укыды. Коммунист студентларга Энгельснең бер әсәрен укырга тәкдим иткәндә, ул болай дип киңәш бирде:

„Әгәр бу әсәр бер укып чыгу белән үк аңлашылмаса, аптырап калырга ярамый. Болай кинәт кенә аңлау һичбер вакытта да, бер кемдә дә булмый диярлек. Ләкин аңа соңыннан, аңа карата кызыксыну тугач, кире кайтып караганда сез аның, әгәр бөтенләе белән булмаса, күп өлешен аңлауга ирешерсез".

Корыч шкафларда Лениннең бик күп калын-калын дәфтәрләре саклана. Ул бу дәфтәрләргә үзе укыган күп кенә китапларны язып аңлаткан, күчермәләр ясаган, конспектлар төзегән. Ленин укыган китаплары турында үзенең фикерләрен шул дәфтәрләргә язган. Аларның характерлы ягы әнә шунда.

Ленин нинди дә булса бер мәсьәлә белән шөгыльләнгән вакытта, бу мәсьәлә буенча таба алган барлык әдәбиятны да җентекләп укый иде. „Россиядә капитализмның үсүе" дигән китапны язу өчен Ленин өч телдә 475 китап укып чыккан. „Империализм—капитализмның иң югары стадиясе" дигән китапны

язу өчен 503 китап һәм газеталардан, журналлардан 353 мәкалә укып чыккан.

Энгельснең һәм Маркснең ул заманда бик сирәк табыла торган „Изге семья“ дигән китабын укыганда Лениннең беренче тапкыр буларак төзегән конспекты саклана.

Ленин иң элек китапның исмен тулысынча күчерә. Аннан соң китап турында яза: „Басма табакның 8 дән бер өлеше зурлыгы форматындагы кечкенә китап (Париж, октябрь 1844), сүз башыннан, эчтәлектән һәм 9 бүлекле тексттан тора...“ Ленин аның кайсы бүлекләрен Энгельс, кайсы бүлекләрен Маркс язганлыгын күрсәтә. Шуннан соң китаптан күчермәләр алып, бүлекләп-бүлекләп бөтен китапның эчтәлеген тулы итеп язып чыга. Иң әһәмиятле күчермәләр астына бер яки ике сызык сыза.

Менә Дебориннең 1909 нчы елда басылып чыккан „Диалектик материализм“ дигән мәкаләсе. Ленин үзе килешмәгән җөмләләр һәм фикерләр астына гади кара карандаш белән сызган һәм алар янына, китапның читенә, түбәндәгеләрне язган: „Төгәл түгел“, „Ялган“, „Чын хакыйкат кеше аңламаслык итеп, җен теле белән язылган. Энгельс мондый магнәсез, буш сүзле тел белән язмый“ һ. б.

Ленин бары тик җидди фәнни китаплар гына укымады. Ул, Маркс һәм Энгельс кебек үк, беллетристика[1] укуны, аеруча классикларның әсәрләрен укуны ярата иде. 1913 нче елда Лениннең анасына Краковтан язган хатында Н. К. Крупская болай дип яза:

— Безнең биредә бик нык сусаган нәрсәбез—ул, беллетристика. Надсонны һәм Некрасовны Володя күңелдән белә диярлек. „Анна Каренина“ның тузып беткән томы инде йөзенче тапкыр укыла. Без үзебезнең беллетристикабызны (Питерда булган бик аз гынасын да) Парижда калдырган идек. Ә биредә рус әдәбиятын бер каян да табып булмый. Кайбер вакытларда Успенскийның 28 томлыгы, Пушкинның 10 томлыгы һ. б. турында букинистларның[2] белдерүләрен көнләшү белән укыйбыз. Володя нәрсәгәдер, үч иткән кебек, зур „беллетрист“ булып китте“...

Лениннең туганнарына язган 300 ләп хаты саклана. Алар төрмәдән, сөргеннән, чит илдән язылганнар. Ленин һәрбер хатта диярлек китаплар турында яза, үзенә китап җибәрүләрен сорый, теге яки бу китапны укып чыгарга киңәш бирә.

1901 нче елда кулга алынып, төрмәгә ябылган сеңлесе Мария Ильиничнага язган хатында Ленин түбәндәге киңәшне бирә:

— Булган китаплардан дөрес файдаланырга, аларны төрлеләндерергә тагын бер тапкыр киңәш бирәм: укуны яки эшне алмаштыру—тәрҗемәдән укуга, язудан гимнастикага, җидди укудан беллетристикага күчү гаять күп ярдәм иткәнен мин бик яхшы хәтерлим...

Ленин комсомолның III нче съездында яшьләр союзларының бурычлары турында речь сөйләде. Ул үзенең речендә, Маркс кешелек дөньясы белемнәренең нык фундаментына таянганга күрә, Маркс таглиматы миллионнарча һәм ун миллионнарча эшчеләрнең йөрәкләренә кереп урнаша алганлыгы турында сөйләде. Маркс кешелек җәмгыяте тарафыннан тудырылган нәрсәләрнең барсын да тәнкыйт астына алып яңадан эшләде.

Ленин, Маркс кебек үк, шундый гигант эш эшләде. Кешелекнең китапларга җыелган белемнәрен тәнкыйт итеп һәм яңадан эшләп, Ленин Маркснең эшен бөек дәвам иттерүче, бөтен дөньядагы йөз миллионнарча хезмәт ияләренең юлбашчысы һәм оештыручысы булды.

---

1) Беллетристика—роман, хикәя, повесть.
2) Букинист—иске китап сатучы.

Ул вакытта Владимир Ильич Горкада яши иде.

Менә Яма авылыннан кечкенә генә бер малай Горкага килде. Зур йорт янында бер кеше басып тора. Малай аның янына килде дә, сорау бирде:

— Абый, Ленин шушы йортта торамы? Ленинне минем бик күрәсем килә иде.

— Алай булса,—диде бу кеше ягымлы гына итеп,—күр! Мин Ленин үзе.

Малай ышанмады, көлде:

— Син нинди Ленин? Ленин гади күлмәк киеп йөримени? Аның киемнәре бик шәптер! Ю-юк... Син Ленин түгел...

Кеше елмая:

— Мин Ленин үзе.

Ә малай ышанмый. Алар бәхәсләшә башладылар.

Берсе әйтә:

— Мин Ленин.

Икенчесе әйтә:

— Юк, син Ленин түгел! Ул важный, ә син простой.

Шул вакыт зур йорттан бер хатын чыкты да:

— Владимир Ильич, кичке салкын төште, сез өйгә керер идегез,— диде.

Владимир Ильич өйгә кереп китте. Ә малай йорт тирәсендә үскән үләннәр өстенә утырды да, бер кая китмичә торды. Бер сәгат, сәгат ярымнан соң теге хатын яңадан чыкты:

— Малай, син әле һаман утырасыңмыни?

— Утырам.

— Бар, өегезгә кайт, вакыт бик соң бит инде.

— Юк, кайтмыйм, Ленинне күрәсем килә минем.

— Син аны күрдең ич!

— Ә мин аның Ленин икәнен белмәдем, һәм аны яхшылап карый да алмадым.

— Бар, кайт, караңгы төште инде, башка вакытта килерсең.

Малай урыннан торды да, Ленинне ничек күрүе турында сөйләр өчен үзләренә, Яма авылына йөгерде.

Ә Горка хәзер Ленин исме белән йөртелә. Хәзер анда ял йорты.

Язып алучы ***С. Мирер.***



СССР Верховный Советы Президиумы указы

ИПТӘШ ИОСИФ ВИССАРИОНОВИЧ СТАЛИНГА СОЦИАЛИСТИК ХЕЗМӘТ ГЕРОЕ ИСМЕ БИРҮ ТУРЫНДА

Большевистик партияне оештыру, Совет дәүләтен төзү, СССР да социалистик җәмгыят төзеп җиткерү һәм Советлар Союзы халыклары арасында дуслыкны ныгыту эшендә күрсәткән гаят зур хезмәтләре өчен иптәш Иосиф Виссарионович СТАЛИНГА,—аның алтмыш еллыгы көнендә,—СОЦИАЛИСТИК ХЕЗМӘТ ГЕРОЕ исмен бирергә һәм бер үк вакытта СССР ның бөек бүләгеп—ЛЕНИН ОРДЕНЫ тапшырырга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
20 декабрь, 1939 ел.

Ленин эшен бөек дәвам иттеручe иптәш Сталинга

Кадерле дус һәм сугышчан иптәш!

Большевиклар партиясенең Үзәк Комитеты сине, Ениннең дустын һәм аның эшен бөек дәвам иттеручене, партиянең һәм совет халкының юлбашчысын—синең 60 еллыгың көнендә кайнар рәвештә котлый.

Пролетар революция эшенә, эшчеләр сыйнфы һәм бөтен хезмәтчел халык эшенә син 40 елдан артык хезмәт итәсең. Син Лениннең партия өчен, пролетариат диктатурасы өчен көрәшендә иң турылыклы көрәштәше булдың. Ленин белән берлектә син куәтле большевиклар партиясен озак еллар буена төзедең һәм чыныктырып килдең. Ленин белән берлектә син 1917 нче елның октябрендә партияне һәм эшчеләр сыйнфын кораллы восстаниегә алып бардың. Лениннең иң якын ярдәмчесе буларак, син октябрь восстаниесен хәзерләүнең бөтен эшенә һәм эшчеләр сыйнфының властьны уңышлы яулап алуына турыдан-туры җитәкчелек иттең.

Чит ил басып алучыларына һәм буржуаз-алпавыт ак гвардиячеләренә каршы илебездә гражданнар сугышы елларында син, иптәш Сталин, революциянең язмышы хәл ителгән барлык фронтларда Ленин җитәкчелегендә Кызыл Армиянең җиңүләрен турыдан-туры рухландыручы һәм оештыручы булдың.

Ленин үлгәннән соң большевиклар партиясе, үзенең юлында торган гаять зур кыенлыкларны җиңеп, синең зирәк җитәкчелегеңдә илебезне социализм җиңүенә китерде.

Халыкның кабахәт дошманнары—троцкийчылар, зиновьевчылар, бухаринчылар—илебездә социализмның җиңүе мөмкинлегенә эшчеләр сыйнфының, совет халкының ышанычын тартып алырга теләделәр, партияне эчтән таркатырга, большевиклар партиясенең бердәмлеген җимерергә, Совет властын һәм социалистик революцияне һәлак итәргә күп тапкырлар маташтылар. Социализм дошманнарына, партия дошманнарына каршы ныклы принципиаль көрәштә, синең житәкчелегеңдә ленинизм өчен көрәштә Үзәк Комитет һәм бөтен партиябез тупланды. Син бер илдә социализм җиңүе мөмкинлеге турындагы Ленинчел теорияне саклап калдың, бу бөек теорияне тагын да үстердең, аның белән партияне һәм Советлар Союзының миллионнарча хезмәт ияләре массасын коралландырдың—бу, революция дошманнарын фаш итүне һәм тармар итүне тәэмин итте.

Синең җитәкчелегеңдә большевиклар партиясе илне социалистик индустриялаштеруне тормышка ашырды, яңа индустриаль учакларны һәм районнарны, авыр һәм җиңел индустриянең беренче классы заводларын, машина төзелешенең куәтле заводларын тудырды. Бу хәл бөтен халык хуҗалыгына техник реконструкция ясауны һәм СССР ны өр яңа оборона средстволары белән коралландыруны тәэмин итте. Синең җитәкчелегеңдә партия авылда тоташтан коллективлаштыру һәм кулакларны сыйныф булу ягыннан бетерү кебек гаять тирән революцион переворот ясады, колхоз строеның җиңүе нигезендә күп миллионлы крестьяннәрнең культуралы таза тормышын тәэмин итте. Илебез куәтле индустриаль держава булып, эре коллектив игенчелек иле булып, җиңеп чыккан социализм иле булып әверелде.

Шушы уңышлар нигезендә Советлар Союзы халыклары культурасының кызу

рәвештә күтәрелүе бара. Совет властына, социализм эшенә чын күңелдән бирелгән совет интеллигенциясе тудырылды.

Партия һәм Совет власты Синең житәкчелегеңдә беренче класслы техника белән коралланган куәтле һәм җиңүчән Кызыл Армияне төзеделәр, ул Ватаныбызны барлык тышкы дошманнардан ышанычлы саклаучы булып тора.

Большевиклар партиясе җитәкчелегендә, эшчеләр сыйнфы крестьяннәр белән союзда булып, кешенең кешене эксплуатацияләвен мәңгегә бетерде һәм СССР да кризисларны да, эшсезлекне дә белмәүче, хезмәт ияләренең материаль хәленең һәм культура дәрәҗәсенең өзлексез күтәрелүен тәэмин итүче яңа социалистик стройны урнаштырды. Көрәшебездәге бу төп йомгакның бөтен дөнья күләмендә тарихи әһәмияте бар, ул бөтен дөнья хезмәт ияләрендә социализм тантанасына ышанычны ныгыта.

Безнең партиябез синең гаят актив һәм турыдан-туры җитәкчелегеңдә күп милләтле куәтле Совет дәүләте төзеде, СССР халыкларының бөек һәм жимерелмәслек дуслыгын—аларның чәчәк атуының һәм җиңелмәслек булуының залогын ныгытты. СССР ның яңа Конституциясе, җиңеп чыккан социализм һәм киң социалистик демократия Конституциясе халык тарафыннан бик хаклы рәвештә Сталин Конституциясе дип аталды.

Ленин кебек үк, син дә, иптәш Сталин, революцион теорияне үстерүгә һәм пропагандалауга һәр вакыт гаят зур әһәмият бирдең һәм бирәсең. Илебездәге һәм бөтен дөньядагы миллионнарча кешеләрнең байлыгы булып әверелгән синең классик теоретик хезмәтләрең империализм һәм пролетар революция эпохасының, җир шарының алтыдан бер өлешендә социализм җиңүе эпохасының яңа шартларында марксизм-ленинизмны тагын да үстерү булып тора. Син дәүләт турында марксизм-ленинизм теориясен киңәйттең, капиталистик чолганыш шартларындагы социалистик дәүләт турындагы тагліматны эшләдең. Партияне марксизм-ленинизм белән коралландырып, син аны оешу ягыннан армый-талмый тупладың. Шушы нигездә безнең партиянең Сталинчыл бердәмлеге тормышка ашырылды.

Синең кайгыртучанлык курсәтүең һәм җитәкчелегең нәтиҗәсендә большевиклар партиясе ирешкән гүзәл уңышларның берсе—кадрларның тиз үсүе, социалистик төзелешнең һәм социализм иле оборонасының күп меңнәрчә яңа работникларының күтәрелүе.

Үзеңнең бөтен көчеңне халыкка бөек хезмәт итүгә биреп,—син, иптәш Сталин, Ленин кебек үк, үз халкыңны яратасың һәм халыктан аерылгысыз булып торасың. Ленин кебек үк, син дә Советлар Союзы һәм бөтен дөнья хезмәт ияләренең кайнар мәхәббәте белән чолганып алынгансың.

Бүген безнең партия һәм Советлар Союзы халыклары, 60 еллыгың көнендә Сине котлап, Ленин—Сталин байрагы астында үзенең Үзәк Комитеты тирәсенә һичбер вакытта булмаганча нык тупланганнар һәм коммунизмның тәмам җиңеп чыгуы өчен алдагы көрәшкә хәзер торалар.

Яшәсен җиңелмәслек большевиклар партиясе, Ленин—Сталин партиясе!

Туганыбыз Сталин, партиянең, эшчеләр сыйнфының, совет җирендәге һәм бөтен дөньядагы халыкларның шатлыгы өчен озак еллар яшә!

Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе Үзәк Комитеты.

20 декабрь, 1939 ел.

ВЛКСМ Үзәк Комитетыннан

иптәш И. В. Сталинга

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Бөтенсоюз Ленинчел Коммунистик Яшьләр Союзы, барлык бәхетле совет яшьләре Сезнең 60 еллыгыгыз көнендә—совет халкының һәм бөтен прогрессив кешелек дөньясының шатлыклы бөек көнендә Сезгә, атабызга, дустыбыз һәм остазыбызга чын йөрәктән комсомолларча кайнар сәлам җибәрәләр!

Сез—мәңгелек Лениннең эшләрен бөек дәвам иттерүче. Сезнең җитәкчелегегездә Советлар Союзы халыклары сыйныфсыз социалистик җәмгыяг төзеделәр һәм бөтен хезмәт иясе кешелек дөньясына капиталистик коллыкның, изелүнең һәм эксплуатациянең богауларыннан котылу юлын күрсәтеп, җиңүле рәвештә коммунизмга баралар.

Совет яшьләре иркен һәм шатлыклы яшиләр. Безне иртәгәсе көн куркытмый. Безнең алдыбызда барлык юллар ачык, безгә хезмәткә хокук, ял итүгә хокук, белем алуга хокук тәэмин ителгән. Боларның барсы өчен без Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясенә, Сезгә, иптәш Сталин, бурычлыбыз!

Совет яшьләренең барлык уйлары һәм өметләре безнең юлбашчыбыз, атабыз һәм остазыбыз, Сезгә юнәлдерелгән! Совет яшьләре үзләренең йөрәкләрендә **Сталин** исмен горурлык һәм шатлык белән йөртәләр.

Сезнең исмегез—һаман җиңә баручы большевиклар партиясенә чиксез бирелгәнлекнең, совет халкына чиксез ышанганлыкның, хезмәт ияләренә карата бетмәс-төкәнмәс мәхәббәтнең символы, дошманнарга карата ачы нәфрәтлелекнең символы.

Социализм иленең яшь егетләре һәм кызлары, барлык яшь буын Сездән, иптәш Сталин, батырлыкка һәм куркусызлыкка, большевистик гадилеккә һәм скромный булырга, көрәшә һәм җиңә белергә өйрәнәләр.

Ленин белән бергә Сез яшьләрнең Коммунистик Союзын төзедегез, Сез комсомол бишеге янында тордыгыз, социализм өчен көрәшләрдә аны тәрбияләдегез һәм чыныктырдыгыз. Сез комсомолны яңа дөньяны төзүчеләрнең куәтле 10 миллионлы армиясенә әверелдердегез, аны коммунизм өчен көрәшнең идеяләре белән рухландырдыгыз, безнең туган анабыз—Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе тирәсенә тупладыгыз.

Безгә барлык хезмәт ияләренең бәхете өчен, коммунизмның бөек идеяләре хөрмәтенә Сезнең җитәкчелегегездә яшәү һәм эшләү шатлыклы. Без Сезне, сөеклебез иптәш Сталин, ышандырабыз ки, комсомол теләсә нинди эштә, теләсә нинди сугышта большевистик партиянең куәтле резервы һәм сугышчан ярдәмчесе дигән югары исемне намус белән аклар.

Үзенең бөек дустына, атасына, остазына һәм юлбашчысына чиксез мәхәббәт тойгысы белән тулган миллионнарча совет яшьләре: безнең туганыбыз, сөеклебез иптәш Сталин, озак, озак еллар яшәгез! дип белдерәләр.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты.

РӘХМӘТ БЕЛДЕРУ

Минем алтмыш еллыгым уңае белән котлаулар һәм яхшы теләкләр җибәргән барлык оешмаларга, җәмгыятьләргә, группаларга, учреждениеләргә, кешеләргә чын күңелдән рәхмәт белдерәм. СТАЛИН.

С. ХӘКИМ

СКУЛЬПТОР

(Орденлы скульптор С. Л. Меркуров мастерскоенда)

Көрешкәнгә еллар үтте инде,
Түбәтәен киеп башына,
Гади эшче кебек, җиң сызганып,
Ул елмаеп баса каршыма.
Шәһәр читендәге йортына без
Барган идек аны күрергә,
Сөйләшергә, сәнгат мастерының
Эше белән танышып йөрергә.
Ул, үзенең көннәр буе чыкмый
Хезмәт итә торган җиренә,
Алып керде безне, артистлар һәм
Композиторларның биредә
Маскалары тора. „Җырларымны
Үтерә алмадылар дуэльдә“,—
Дигән кебек карый Лермонтов та,
Ихтиярсыз шул чак күңелдә,
Кабатлыйсың аңа җавап итеп
Яңа туган шигырь юлларын:
„Без алмашка килдек яңа буын;
Энеләрең синең, улларың“
Тау өстенә кунган бөркет кебек,
Иөзе белән безгә борылып,
Маяковский тора алгы сафта
Коңгыр кара чәчен туздырып.
— Республикадагы каләмдәшләр,
Баш шәһәргә сәламы килдегез?
„Җырчы шагыйрләрнең яхшыларын
Һәм төрлесен безгә бирегез!“
Скульптор төзә, кыю төзә,
Ышанып ул иҗад көченә.
Юлбашчыда булган бөеклек һәм
Гадилекне алып эшенә.
Әйбәт куллар гына җитми әле;
Һәйкәлләрне оста куярга,
Без яшәгән илнең матурлыгын
Йөрәк белән кирәк тоярга.

1939.

ЯҢА ЕЛ

Яу, аппак кар,
Шатланып яу,
Яңа ел хөрмәтенә,
Яңа елның кочагында
Бәхетле тормыш килә.

Яу, аппак кар!
Мактанып яу,
Киң басулар өстенә,
Җырда сөеп макталырлык
Чәчәкле тормыш килә.
Шатлыклы булсын яңа ел,
Дулкынлап яу, ак чәчәк!
Бүгенге көн гөл бакчасы,
Тагы да матур киләчәк.

Яңа ел бөек Ватанга
Җиңүләр алып килер.
Хәтфә төсле киң басулар
Тиңсез мул уңыш бирер.
Үткәнебез зур җиңүле,
Үткәнебез мактаулы.
Үткән ел һәм үткән көннәр
Җиңүләр белән данлы.

Хуш, үткән ел!
Хөрмәтле син,
Сөеп сине мактыйбыз.
Синең шатлыкларың белән
Яңа елга атлыйбыз.

Яңа елга атлаганда
Беренче сүз Сталин!
Иң беренче котлавыбыз
Сиңа, иптәш Сталин!

Г. Латыйп.



9 нчы январь

(М. Горькийнең шул исемдәге әсәреннән өзек)

...Шау-шу үсте. Каты ачу белән кычкырган тавышлар ишетелде, мыскыллап эндәшүләр яңгырады. Сау акыл, магнәсез комачауга бәрелеп җимерелде һәм сөйләшми башлады. Кешеләрнең хәрәкәтләре борчулырак, ыгы-зыгылырак булып китте; елгадан ачы суык сирпелде. Штыкларның очлары хәрәкәтсез ялтырыйлар иде.

Бер-берсенә эндәшеп һәм арттан кысуга буйсынып, кешеләр алга бардылар. Яулыклар күтәреп киткәннәре бер якка борылып, халык төркеме эченә кереп югалдылар. Ләкин алдагыларның барсы да—ирләр дә, хатын-кызлар да, яш үсмерләр дә,—шулай ук яулык болгадылар.

— Нинди ату булсын анда? Ни өчен?—диде, сакалына чал кергән, олгайган бер кеше.—Алар бары тик күпергә генә җибәрмиләр, янәсе, туптуры боздан барыгыз.

Шунда кинәт, һавада тигезсез һәм коры гына нәрсәдер чәчелде, калтырандә, күз күрмәгән уннарча камчы белән халык төркеменә сукты. Бер секундка кинәт бөтен тавыш катып калган төсле булды. Масса акрын гына алга хәрәкәтләнүендә дәвам итте. Берәүсе төссез тавыш белән:

— Чын пуля белән түгел!..—диде, әллә белеп әйтүе булды, әллә сорады.

Ләкин, тегендә-монда ыңгырашулар яңгырады, берничә гәүдә халык аяк астына егылды. Бер хатын, ухылдап, кулы белән күкрәгенә ябышып, тиз-тиз атлап, үзенә каршы төбәлгән штыклар өстенә китте. Аның артыннан, аны чолгап алып, аның алдына чыгып, тагынтагын кешеләр йөгерделәр.

Менә тагын залп белән мылтык шартлады. Монысы тагын да катырак, тагын да тигезсезрәк. Койма янында басып торучылар такталарның калтырануларын сизделәр, әйтерсең, кемдер күренмәс тешләре белән аларны усаллап тешләде. Бер пуля, койма тактасы буена сыптырылып, аңардан вак кына

йомычкалар куптарып кешеләрнең йөзләренә ыргытты. Кешеләр икешәрләп, өчәрләп аудылар, эчләрен тотып җиргә чүгәләделәр, аксый-аксый каядыр йөгерделәр, кар өстендә үрмәләп йөрделәр һәм кар өстендә бөтен җирдә ачык кызыл таплар калкып чыкты, алар җәеләләр, буланалар, күзләрне үзләренә тарталар иде... Халык төркеме бераз артка чигенде, бер мәлгә туктады, шак катып калды.

Һәм кинәт, йөзләрчә тавыш белән, ерткычларча, йөрәк әрнеткеч рәвештә улаган тавыш яңгырады. Ул күтәрелеп, ачы сызлану, коточкыч курку, протест, хәсрәтле аңлашылмау һәм ярдәм итәргә чакыру тавышларыннан торган чуар болыт булып, туктаусыз һәм тоташ калтыранып, һава буйлап агылды.

Төркем-төркем кешеләр башларын бөгеп, үлекләрне һәм яралануучыларны җыеп алу өчен алга ташландылар. Яралануучылар да шулай ук кычкыралар, йодрыклары белән яныйлар иде. Барлык кешеләрнең йөзләре кинәт башка төс алды һәм барлык күзләр куркып шашкан рәвештә ялтырадылар. Кешеләрне кинәт чолгап алып, җил коры яфракларны бер өемгә себереп өйгән кебек, гәүдәләрне себереп түгә торган, һәм качу өчен сукыр рәвештә омтылуның кыргый давылында барсын да каядыр сөйри, куалый торган гомуми кара куркыныч—паника юк иде. Туңып каткан тимердәй өтеп ала торган коточкыч куркыныч кына бар; ул, йөрәкне боз кебек туңдыра, гәүдәне кысып ала һәм: карга җәелгән канга, канаган йөзләргә, кулларга, канга буялган киемнәргә, куркулы ыгы-зыгылар арасында коточкыч тыныч ятучы үлекләргә күзне зур ачып карарга мәҗбүр итә иде. Биредә ачы аптырау, кайгылы, көчсез ачу, нишләргә белмәү, сәер рәвештә хәрәкәтсез калган күп күзләр, җыерылган кашлар, каты кысылган йодрыклар, тартышулы хәрәкәт һәм кискен күп сүзләр бар иде. Ләкин, кешеләрнең күкрәкләренә һәммәсеннән дә бигрәк, күңелне үтерә торган салкын гаҗәпләнү тулган төсле булды. Шушыңардан берничә минут кына элек, алар бит, үз алларында бу баруның максатын ачык күреп баралар; алар алдында әкияттәгечә мәһабәт сурәтләнеп теге сурәт басып тора, алар аңа сокланалар, аны сөяләр һәм эчләреннән аңа зур өмет баглаганнар иде. Ике залп, кан, үле гәүдәләр, ыңгырашулар, һәм—барсы да өзгәләнгән йөрәк белән көчсез рәвештә, соры бушлык алдында калдылар.

Нәрсә беләндер чолганып алынып, аны өзә алмагандай, бер урында таптандылар; берәүләре сөйләшмичә һәм борчылулы рәвештә яралануучыларны күтәреп ташыйлар, үлекләрне җыялар; икенчеләре—сәер бер хәрәкәтсезлектә аларның эшләренә төштәгедәй шак катып карап торалар. Күпләре солдатларга үпкәләү, шелтәләү һәм сүгенү сүзләре кычкыралар, кулларын болгыйлар, бүрекләрен салалар, ни өчендер баш ияләр,—кемнеңдер коточкыч ачуы белән куркыталар иде.

Солдатлар,мылтыкларын аяклары янында тотып, бер дә кыймылдамый тик торалар, аларның йөзләре дә шулай ук хәрәкәтсез, яңак тиреләре киерелгән, яңак сөякләре очланып калкып тора. Һәммәсенең дә күзләре ак булып һәм иреннәре туңып ябышкандай күренәләр.

Халык төркемендә кемдер, шашкансыман каты кычкырды.

— Ялгыш! Ялгышлык килеп чыкты, туганнар!.. Башкалар дип аңладылар! Ышанмагыз!.. Килегез, туганнар, аңлатырга кирәк!..

Яш үсмер бер малай фонарь баганасына менеп:

— Гапон—хиянәтче!—дип акырды.

— Я, нәрсә, иптәшләр, күрәсезме ничек каршы ала сезне?

— Тукта, бу ялгышлык! Син аңла, болай булу мөмкин түгел.

— Яралануучыга юл бирегез!

Ике эшче белән бер хатын-кыз, озын буйлы ябык кешене җитәкләп киләләр; ул бөтенләй карга буялган, аның пальто җиңе эченнән кан ага. Аның йөзе агарган, тагын да бигрәк очлайган. Ул күгәренгән ирнен зәгыйф кенә кыймылдатып:

— Җибәрмәсләр дип әйттем бит мин!.. Алар аны яшерәләр, нәрсә ул аларга халык!—дип пышылдады.

— Атлы казаклар!

— Кач!

Солдатлардан торган стена калтыранды һәм агач капка кебек ике якка ачылып китте, алар арасыннан, биеп, пышкыра-пышкыра атлар уздылар, офицерның кычкырган тавышы яңгырады, атлылар-

ның баш очларында һаваны кисеп кылычлар күтәрелде, алар көмеш тасмадай ялтырап, барсы да бер якка таба селтәнделәр. Халык төркеме, чайкалып, дулкынланып, нәрсәдер көтеп, ышанмыйча басып торуында дәвам итте.

Тынрак булып калды.

— Ма-арш!—дигән, шашынган тавыш яңгырады.

Кешеләрнең йөзләренә өермә килеп бәрелгәндәй һәм аяк асларында җир зырылдап әйләнгәндәй булды, барсы да, берсен-берсе төртеп егып, яраланучыларны ташлап, үле гәүдәләр өстеннән сикереп чыгып йөгерә башладылар. Атларның авыр дөпелдәгән аяк тавышлары куып килә, солдатлар акыралар, атлары—яраланучылар, егылып ятучылар, үлеләр өстеннән сикерәләр. Кылычлар ялтырашалар, коточкыч курку һәм сызланып кычкырулар күтәрелә. Аратирә корычның сызгырып сөяккә килеп бәрелүе ишетелеп китә.

— О-о-о!..

Солдатлар кылычларын селтәп, кешеләрнең башларына кизәнәләр, шул сугу уңаена аларның гәүдәләре янтая. Аларның йөзләре кызыл һәм күзсез иделәр. Атлары башларын чайкап, тешләрен ямсез ыржайтып кешниләр.

Халыкны урамнарга куып керттеләр.. Атлар тыпылдап баскан тавыш еракка китеп югалгач, кешеләр тыннары буылып туктадылар, акайган күзләре белән бер-берсенә карашып алдылар. Бик күбесенең йөзенә оялчан елмаю төсе чыкты һәм кайсыдыр:

— Әй йөгердем дә соң!..—дип кычкырып көлде.

Аңа:

— Йөгерерсең!..—дип җавап бирделәр.

Шунда кинәт төрле яктан: гаҗәпләнү, курку, ачулану тавышлары яңгырады.

— Нәрсә соң инде бу, туганнар, ә?

— Үтереш бара, православныйлар!

— Ни өчен?

— Менә сиңа—хөкүмәт!

— Турыйлар, ә? Ат белән таптаталар!..

Бер - берсе белән үзләренең ачуларын уртаклашып, бер нәрсә аңлый алмыйча бер урында таптандылар.

Ни эшләргә кирәклеген аңламыйлар, берәү дә китми, һәрберсе, тойгыларның чуар чәбәләнмәсеннән ычкынырга чара табарга тырышып, башка берсе янына килеп кысыла, бер - берсенә куркулы кызыксыну белән карыйлар. Шулай да, куркудан бигрәк гаҗәпләнгән бу кешеләр, тыңлап, каранып нәрсәдер көтәләр. Барсы да, шак катып гаҗәпләнүдән аңгырайган һәм ватылган иделәр. Гаепсезләр каны белән сугарылган, көтелмәгән коточкыч куркыныч, магнәсез һәм кирәкмәс бу минутта, бу гаҗәпләнүдән аңгыраю күңелләрнең табигый рәрештә бергә кушылуына комачаулык итә иде.

Яш бер тавыш каты итеп:

— Әй! Яраланучыларны җыярга килегез! — дип кычкырды.

Бөтен кеше хәрәкәткә килде, бик тиз, елгага чыга торган урынга киттеләр. Аларга каршы, урамга, кардан шуышып, һәм аякларына көч-хәл белән басып чайкалып, канга баткан, карга буялган, имгәнгән кешеләр килә башлады. Ул кешеләрне кулларына алдылар, күтәреп бардылар, извозчикларны туктатып аларга утырган кешеләрне куып төшереп, шуңа утыртып каядыр алып киттеләр. Бөтен кеше борчулы, күңелсез һәм сөйләшмәс булып калды. Яраланучыларны күзләре белән чамалап карадылар, дәшми-тынмый гына нәрсәдер үлчәделәр, чагыштырдылар, үзләре каршына билгесез, формасыз, кара күләгә булып килеп баскан куркыныч сорауга уйга чумып җавап эзләделәр. Ул сорау, күптән түгел уйлап чыгарылган кәһарман патшаның, рәхимлелек һәм яхшылык чишмәсенең сурәтен юкка чыгарды. Ләкин, бу сурәтнең инде җимерелгәнлеген тел белән әйтергә бары бик азлар гына батырчылык итте. Моны икрар кылу кыен, бу бит үзеңне бердән-бер өметтән мәхрум итү булачак иде...

Кызгылт ямаулы пальто кигән, пеләш башлы кеше килеп чыга, аның тонык баш сөяге хәзер канга буялган, башы һәм иң башлары салынып төшкән, аяклары хәлсезләнеп сыгыла. Аны, тузган бөдрә чәчле, киң җилкәле яланбаш бер яш егет белән, өстенә ертылып беткән тун кигән, җансыз катып калган йөзле бер хатын җитәкләп алып киләләр иде.

Яраланучы кеше:

— Тукта әле, Михайло, ничек соң бу? Халыкка атарга рөхсәт ителми!.. Бу эш булырга тиеш түгел, Михайло, — дип мыгырданды.

Егет:

— Булды шул! — дип кычкырды.

Хатын кайгырып:

— Аттылар да, турадылар да!..—дип куйды.

— Димәк, шулай эшләргә приказ булган, Михайло...

Егет ачу белән:

— Булган шул! — дип кычкырды.— Ә син, безнең белән сөйләшеп торырлар дип уйлаган идеңме? Стакан белән аракы китереп бирерләр дип белдеңме?

— Тукта әле, Михайло...

Яралы кеше, аркасы белән стенага терәлеп туктады да:

— Православныйлар!.. Ни өчен үтерәләр безне? Нинди закон буенча?.. Кем бойрыгы буенча? — дип кычкырып җибәрде.

Кешеләр аның янынннан башларын түбән салындырып үтәләр иде.

Икенче урында, койма почмагында, берничә дистә кеше җыелган, урталарында кемдер, тыны-көне бетеп, борчылып һәм усал тавыш белән тиз-тиз сөйли:

— Гапон кичә министрда булды, ул нәрсә буласын барсын да белгән, димәк, ул безгә хиянәт итүче, ул алып килде безне үлемгә!

— Аңа нинди файда?

— Ә мин каян белим?

Һәр җирдә болганышу башланды, һәр кайсы алдына, әле ачык булмаган сораулар килеп басты, шулай да бу сорауларның әһәмиятен, тирәнлеген, рәхимсез һәм ныклы җавап соралганын һәр кем сизә иде. Болгану турында, читтән ярдәм килүгә ышану, мохтаҗлыктан могҗизәле рәвештә коткаручыга өметләнүләр бик тиз көйрәп янып бетте.

Урам уртасыннан, аналарча шәфкатле йөзле, кайгылы зур күзле, начар гына киенгән, тулы гәүдәле бер хатын бара. Ул җылый һәм уң кулы белән, канга буялган сул кулын тотып:

— Ничек эшләрмен инде? Балаларга нәрсә ашатырга?.. Кемгә шикаят кылырга?.. Православныйлар, патша да халыкка каршы булгач, ул халыкның яклаучылары кайда соң? — дип сөйләнә иде.

— Димәк, халыкка закон юк?

Кайберләре тирән сулап көрсенделәр. Башкалары кычкырмый гына сүгенделәр.

Каяндыр кискен, усал кычкырган тавыш ишетелде:

— Ярдәм алдым—улымның аягын сындырдылар!..

— Петруханы үтерделәр!

Тавышлар күп иделәр, алар колакны ярып керәләр, һәм үч алырга өндәгәндәй яңгыраган бу кискен тавышлар, усаллык хисләрен, үтерүчеләрдән сакланырга кирәклеген аңлауны уяталар иде. Агарынган йөзләргә ниндидер төпле бер уйга килү төсе чыкты.

— Иптәшләр! Шулай да без шәһәргә барыйк... бәлки, ни дә булса булдырырбыз... Азлап-азлап кына барыйк!

— Үтереп бетерерләр...

— Әйдәгез, солдатларга сөйлик, халыкны үтерергә закон юклыгын, алар, бәлки, аңларлар!

— Бәлки, бардыр, без каян белик?

Төркем, акрын-акрын, ләкин, туктаусыз үзгәрә барып, зур халык массасы төсенә керде. Яшләр вак-вак группаларга аерылып, барсы да бер якка, яңадан елгага таба киттеләр. Яралыларны, үлүчеләрне һаман китереп торалар, җылы кан исе килә, ыңгырашулар, әндәшүләр яңгырап тора иде.

— Яков Зиминнең нак маңлаена...

— Рәхмәт атабыз патшага!

— Әйе, каршы алды!

Берничә каты сүз яңгырады. Моннан чирек сәгать элек, халык төркеме шундый сүзләрнең берсе өчен генә дә өзгәләп ташлаган булыр иде.

Бер кечкенә кыз бала йөгерә һәм бөтен кешегә:

— Әнине күрмәдегезме? — дип кычкыра иде.

Кешеләр аңа бер сүз дәшми генә борылып карап юл бирделәр.

Аннары, кулы сынган хатын тавышы ишетелде:

— Биредә мин, биредә...

Урам бушады. Яшләр тизрәк китә башладылар. Яшләр хиткән якка күзләрен күтәрми генә карап, икешәрләп-өчәрләп олы кешеләр дә йөзләрен чытып, ашыкмый гына каядыр баралар. Аз сөйлиләр... Тик ара-тирә генә, ачынуга чыдый алмыйча, кайберләре:

— Димәк, халыкны бер читкә ташладылар инде? — дип әйтеп куялар.

— Каһәр төшкерләре, кеше үтерүчеләр!

ИСТӘЛЕКЛӘР

Валериан Владимирович Куйбышев Ленин һәм Сталин тарафыннан тәрбияләнгән большевиклар карт гвардиясенең иң күренекле вәкилләреннән берсе. Ул кече яштән үк революцион эшкә керешә. 1905 нче ел революциясенә актив рәвештә катнаша. Гражданнар сугышы елларында революциянең дошманнарына каршы батырларча сугыша. Кызыл Армия җитәкчеләреннән берсе була.

Иптәш Куйбышев халык хуҗалыгын яңадан кору эшендә үз-үзен аямыйча эшләде. Ленин һәм Сталинның бөек эшенә һәр вакыт турылыклы булды. Партиянең бердәмлеген ул нык саклады, халык дошманнарын, хыянәтчеләрне рәхимсез рәвештә тар-мар итеп килде. Шунлыктан троцкийчылар, бухаринчылар һәм башка контрреволюционерлар Куйбышевны дошман күрделәр. Алар бу корыч большевикны явызларча үтерделәр.

Быел иптәш Куйбышевның үтерелүенә 5 ел тулды. Валериан Владимирович Куйбышев турындагы якты истәлек совет халкының йөрәгендә мәңге сакланыр!

Мин Москвага килгәндә Валериан партия Үзәк Комитеты секретарьләренең берсе иде инде.

1927 нче елда, партиянең XV нче Съездыннан соң, Валериан Владимировичны Политбюро члены итеп сайладылар, ә тиздән ул СССР Халык Комиссарлары Советы Председателенең урынбасары итеп билгеләнде.

Лениннең һәм Сталинның турылыклы һәм эшчән шәкерте Валериан Владимирович партия дошманнарына каршы нык көрәште, бөек социализм төзелешен җимерергә маташучы троцкийчы - бухаринчыларны һәм башка контрреволюционерларны рәхимсез рәвештә фаш итте.

Партиянең генераль юлы өчен көрәштә ул үз-үзен аямады. Ул бу көрәш өчен барлык көчен һәм тормышын бирде.

Валериан Владимирович иптәш Сталинның иң якын ярдәмчеләреннән берсе булалак, аның күрсәтмәләрен үтәп, беренче һәм икенче бишьеллыкларның гаять зур планнарын төзү эшенә җитәкчелек итте. Ул планнар төзү белән генә чикләнмәде, аларның үтәлешен дә тикшереп барды.

Ул Арктиканы үзләштерү эшенә, илнең җир асты байлыкларын өйрәнүгә, совет авиациясенә, машина төзелешенә, электростанция һәм яңа предприятиеләр төзүгә зур игтибар бирде.

Һәрбер эштә дә, һәр вакытта да күтәренкелек һәм дәрт белән бирелеп эшләүче Куйбышевның эшләгән эшләрен санап чыгу, гомумән, кыен.

Үзенең эше бик күп булуына да һәм эшенең җидди булуына да карамастан, аның төсе бер дә үзгәрми торган иде.

Ял сәгатләрендә ул шаярырга, көләргә ярата, үзенең тирә-юнендәге кешеләрне дә шатландыра белә иде. Без ул вакытта Москва янындагы дачада тора идек. Валериан, сеңлебез Маруся, аның иптәше һәм кунаклардан тагын кемдер берәү — барсы бергәләп поезд белән Москвага бару өчен станциягә киттеләр.

Валериан дулкынланган хәлдә кире кайтып керде. Ул ялгыз гына иде. Ул барсының да поездга сикереп менүләрен, аны калдырып китүләрен сөйләде.

Без, билгеле, гаҗәпләндек. Берничә минут үтүгә Маруся кайтты, ә бераздан аның ире Димитрий кайтып керде. Поездга сикереп менгәндә этәреп җибәрдең,—дип Маруся Валериан Владимировичка үпкәли. Ә Димитрийгә исә, поезд барганда сикереп төшеп калырга туры килгән.

Алар бу эштә кемнең гаепле булуы турында үзара бәхәсләшәләр. Воля этеп төшердең дип Марусягә үпкәли, ә Маруся Волягә...

Берничә минуттан соң башкалар да кайтып керделәр. Кемнеңдер кулы бәйләнгән, Валериан артыннан ул поездан сикереп төшкәндә, чак-чак кына вагон астында калмаган.

Алар бәхәсләшәләр, бер-берсенә үпкәлиләр... Без аптырашып, аларга карап тыңлап торабыз. Кем гаепле булуына һич тә төшенә алмыйбыз.

Кинәт шаркылдап көлгән тавыш яңгырап китә. Барсы да поездга кичеккәннәр, ә бәхәсне үзләре уйлап чыгарганнар икән. Билгеле, боларның барсын да Валериан уйлап тапкан.

Шушы шаяруы миңа аның Тамбовтагы һәм балалык вакытынгады шаяруларын хәтерләтте.

Ул җыр һәм музыканы, балачагындагы кебек үк, ярата иде. Җыр һәм музыканы рәхәтләнеп тыңлагач, ул музыка уйнаучыга яки җырчыга рәхмәт белдерергә ашыга иде. Хор белән җырлаганда ул үзен бик иркен тота иде.

Җыр вакытында ул кайчак кемгә дә булса ачуланып ала. Теге кеше бу ни өчен ачулана икән дип аптырашта кала. Соңыннан бар да аңлашыла, эш болай булган икән: җырлаган чакта теге кеше сөйләшкән, бер урыннан икенче урынга күчкән.

Валериан балаларны бик ярата иде. Туганнарының күп сандагы балалары белән шаярып ул шактый гына вактын үткәрә торган иде. Балалар да аны яраталар һәм аның белән очрашуны түземсезлек белән көтәләр иде. Менә шушы картина күз алдыннан бер дә китми: аның кызы Галя кечкенә чагында бер кулы белән биленә таянып, икенче кулына яулык тотып, әтисенә таба биеп барса, Валериан үзе дә чүгәләп аңа каршы биеп китә торган иде.

Тирә-юндәгеләр „Ах, дуб, дуба-дуба“, —дип җырлыйлар һәм кул чабып торалар.

Валерианның күзләре бу чакта, бала вакытындагы кебек үк, яна башлыйлар, зураялар.

Ул Крымда ял иткән вакытта, Артектан пионерлар аңа кунакка килделәр. Валериан балалар белән көнне бик күңелле үткәрде. Алар белән ачык һавада йөрде, аларга ни дә булса бирәр кызыклы нәрсә күрсәтергә тырышты, уеннар оештырды.

Бер вакыт ул балаларны тирга алып китте. Атуда балалар үзләренең сәләтлелекләрен күрсәтергә җай чыгуга бик шат иделәр. Валериан мишеньгә барысыннан да яхшырак тидерсә дә, ләкин ул үзенең атуыннан канәгат түгел иде. Ул:

— Ешрак күнегү ясарга кирәк, юкса мин начар ата башлаганмын, — диде. Кулына карандаш алып, мишеньгә: „Бик начар!“—дип язып куйды. Ул мишеньне балалар истәлек итеп Артекка алып киттеләр.

Барсы да өстәл янына җыелгач, Валериан Владимирович кемнең нәрсә белән кызыксынуын, кемнең нәрсә яратуын сораша башлады.

Балалар берничә сәгат эчендә үк аңа ияләшеп җиттеләр һәм кыю рәвештә, бер-берсеннән уздырып, сөйләшә башладылар.

Аларның берсе сәяхәт итәргә ярата, икенчесе — радионы, өченчесе—укуны ярата икән. Алар арасында шахматны, атуны, краб тотуны яратучылар да табылды.

— Ә сез, иптәш Куйбышев, нәрсә яратасыз?—дип сорадылар балалар.

— Минме?... мин бар нәрсәгә караганда да пионерларны яратам. Ә минем нәрсә эшләргә яратуымны сорасагыз?.. Мин барсын да эшләргә яратам. Мин һәрбер эшне сөям. Мин төрмәдә столярлык һәм китап төпләүчелек эшенә өйрәндем. Аннан соң слесарь да, фрезеровщик та булдым. Мин барсын да яратам.

Аннан соң бер малай белән шахмат уйнагач:

— Шахмат уйнарга яратам!—диде."

Бер кечкенә пионер белән биллиард уйнагач, аның башыннан иркәләп сыйпаганнан соң, көлемсерәп:

— Биллиард уйнарга яратам!—диде.

Краб тотарга яратучы малайга карап, елмаеп:

— Краб тотарга да яратам ¦ Барсын да яратам...—дип куйды.

Балалар Валериан Владимировичтан үзе турында, фронтта күргәннәре турында сөйләвен үтенделәр. Ул аларны диванга утыртты, җиләк-җимешләр китерде һәм үзе катнашкан сугышлар турында аларга озак сөйләде. Армиядә 12 яшьлек Ваня исемле малайның булуын, аның разведкаларда катнашып, әһәмиятле мәглүматлар китерүе турында сөйләде.

— Ә ул Ваня хәзер кайда соң?—дип сорадылар балалар.

Горький шәһәре. А. М. Горький исемендәге балалар тимер юлында. РӘСЕМДӘ: машинист ярдәмчесе Борис Черепенников.

В. Храмцов фотосы. (ТАСС фото-клишесе).

— Мин аны фронттан укырга җибәрдем. Ул үзе китәргә бик озак күнмәде, хәтта җылап та карады. Мин аны үз атыма, алга атландырдым да: „Я, үз иптәшләрең—сугышчыларың белән саубуллаш, һәм галим, акыллы булырга аларга сүз бир!"—дидем.

— Илтеп тә куйдыгызмы?—дип кычкырып җибәрде бер малай.

— Әйе, илттем, хәзер ул инженер. Заводта эшли. Коммунист.

— Мин китмәс идем, сездән яшеренгән булыр идем.

— Ул да миңа юл буе: „Юкка сез, иптәш Куйбышев, мине аерасыз, юкка гына... Миңа сездән яшеренергә кирәк булган икән, ә мин аңа төшенмәгәнмен..."—диде.

Төнлә факелләр кабызып, барсы да диңгезгә краб тотарга киттеләр.

Иң алда озын буйлы бер пионер бара, ул яндырылган факел тоткан. Аның факелы паркның караңгы аллеяләрен начар яктырта. Юлларда һәм куакларда ниндидер фантастик шәүләләр һәм таплар күренә. Балалар Валериан Владимировичны чолгап алалар, ахыры, төн караңгылыгыннан куркалар булса кирәк, ләкин берсенең дә үзен иптәш Куйбышевка куркак итеп күрсәтәсе килми.

Көчле һәм ябышучан кыскычлары белән кулга авырттырырлык итеп ябышканчы, крабның үзен эләктереп алу бик күңелле. Валериан Владимирович шатлыклы елмаеп, краб тоту эшенә катнашты.

Балалар бик соң гына кайтып киттеләр. Кунакчыл, шат күңелле, ягымлы Валерианнан аерылып китәселәре килми иде аларның.

— Иптәш Куйбышев безне озата чыкты. Безнең машина юл борылышына кереп югалганчыга кадәр ул кул болгап безне озатып калды...—дип сөйләделәр Артек пионерлары.

Валериан шахмат, волейбол, биллиард уйнарга ярата иде.

Һәр уенны да ул кызыксынып уйный, ә инде җиңеп чыкса, аның йөзе, балачагындагы кебек үк, шатлыклы елмая иде.

Волейбол мәйданыннан җиңүче булып киткәндә:

— Менә шәп кайнаштык,—диде ул.

Аның шатлануында, кайнарлануында балаларча гадилек һәм балаларча куану сизелеп тора иде.

Яшелчәләрне ярату аңарда балачагыннан ук килә. Безнең Кукчәтауда җиләк-җимеш бик аз иде, кишер, шалкан, борчак кебек әйберләр татлы сый булып хезмәт итәләр иде.

Морозовкада дачада торганда берничә түтәл ясап, анда борчак чәчә торган идек.

Бер вакыт Воля дачага килде дә:

— Әйдәгез, көтү булып йөрик,—диде. Без барыбыз да борчак түтәленә юнәлдек. Һәм „көтү" булып йөрдек, ягни борчак кузагы ашадык.

Валериан кесәләрен борчак кузагы белән тутыра, шахмат тактасы янында бик тирән уйланып, уйнап утырганда, кинәт кесәсеннән борчак алып ашый һәм үз тирәсендә утыручыларны да сыйлы башлый. Дачага беренче тапкыр килүчеләрне бу хәл гаҗәпкә калдыра торган иде.

Безнең өчен Валериан Владимирович иң якын кеше иде. Без барыбыз да аңар көчле мәхәббәт белән карый идек. Ул безгә балачагыннан ук һәр яктан үрнәк булып торды.

Аның эшсез вактын бик сирәк очратырга туры килә иде. Тыгызлап тутырылган портфелен хәтта ял көннәрендә дә дачага алып килә һәм берничә сәгат буена эшләп утыра торган иде.

Эше бик тыгыз булуга да карамастан, һәрберебезнең хәлен сораша, бер минутка гына булса да эштән аерылып тора иде.

— Иң олы яштәгедән башлап һәрберсе турында да сөйлә, — ди торган иде ул. „Иң олы яштән башлап" дигәне, ашыгыч арада, кемне дә булса беребезне онытып калдырмас өчен әйтелгән сүз иде.

Без аның белән шатлыгыбызны да һәм кайгыбызны да уртаклаша торган идек. Һәм ул безнең белән бергә кайгыбызны да, шатлыгыбызны да кичерә иде.

1934 нче елның февраль аенда Валерианның кызы Галяга 15 яшь тулды. Аның туган көнен бәйрәм итү өчен дуслар һәм туганнар җыелдылар. Бәйрәмчә итеп хәзерләнгән өстәл янында сөйләшүләр, көлүләр, шаярулар ишетелде. Ә Валериан һаман кайтмый. Без аны һаман көтәбез. Менә ул арып-талып, борчулы йөз белән кайтып керде, шулай да үзе бу шатлыклы кичәгә катнашырга тырышты.

Чиратлашып һәр кем үзенең тормышыннан нинди дә булса бер кызыклы хәл сөйләргә тиеш. Барысы да сөйлиләр, барысы да көләләр.

Менә чират Валерианга җитте. Ул гафу үтенгәндәй:

— Кызганычка каршы, хәзергә мин кызыклы бер нәрсә дә сөйли алмыйм, минем уйларым һәр вакыт менә шушы хат белән, — диде һәм ул кесәсеннән хат алып укый башлады:

„Москва шәһәре. Челюскинчеләрне коткару комиссиясе председателенә. Кадерле Куйбышев иптәш! Минем әткәемне коткарыгыз. Мин үземнең әткәемне бик яратам...Ада..."

Кәкре-бөкре хәрефләр белән язылган бала хаты кулдан кулга йөри... Валерианның күзләре бик кайгылы.

Челюскинчеләрне коткару комиссиясендә эшләгән вакытта, Валериан бик борчулы йөрде. Бик сирәк көннәрдә генә ул тыныч йоклый торган иде. Телефон звоноклары бер дә тукталмыйча шалтырап тордылар.

Очучы Ляпидевскийнең ун кешене боз лагерыннан алып китүе турында Валерианга телефон аша хәбәр ителгән вакытта, мин аның сөйләшүен тыңлап тордым. Валериан Владимирович шат тавыш белән сөйли. Ул телефон трубкасын куйганнан соң:

— Тагын кемгә шалтыратырга, тагын кемгә сөйләргә икән? — диде.

Аңар күп уйланырга туры килмәде. Телефон шалтырады. Валериан шатланып җавап бирде:

— Чынлап, чынлап, дөрес... Барлык хатын-кызлар һәм балалар коткарылганнар.

Боз өстендә алты кеше генә калгач, аның ничек дулкынланганлыгын сез белсәгез иде!

— Хәзер аларның һәлак булулары бик җиңел. Алты кешегә стихиягә каршы көрәшүе бик кыен.

Аннан соң тагы шатлык—соңгы алты челюскинче дә коткарылган! Тагын телефон буенча кызу-кызу сөйләшүләр...

Валериан коткарылучыларның туганнарыннан һәм танышларыннан килгән

хатларның барсын да җыя барды. Ул аларның барсын да: кәкре-бөкре хәрефләр белән балалар тарафыннан язылганнарын да, зурлар тарафыннан машинада басылганнарын да үзе укыды.

Балалар үзләренең рәхмәт хатлары белән бергә боз лагерының, очучыларның, Шмидтнең рәсемнәрен дә җибәрделәр. Валериан Владимирович аларның һәрберсен дә зур игтибар белән карап чыкты һәм аерым бер папкага җыеп барды.

1934 нче елның азагында, Валериан Владимировичка электә үзе булган урыннарга — Казахстанга һәм Таҗикстанга барырга мөмкинлек булды.

Бередә аның балачагы узды, бередә ул ак генералларга каршы сугышты, басмачыларга каршы һәм кулакларга каршы көрәште. Бередә ул Совет властын урнаштырды. Ундүрт ел үткәннән соң күргәч ул таныш краен таный алмаган.

— Барысы да яңача, яңабаштан корылган, үзгәргән. Халыклар да үскәннәр, үзгәргәннәр. Анда патша хөкүмәте вактында күрергә мөмкин булган изелгәннәрне һәм хәерчеләрне хәзер инде очрата да алмыйсың, — дип сөйләде безгә Валериан, — Кызыл Армия комнар арасында каты сугышлар алып барган урында хәзер тимер юл сузылган. Электәге сусыз яткан ком сәхраларында хәзер яхшы сугарыла торган мамык кырлары җәелеп ята. Безнең совет мамык кырлары! Безнең мамык кырларының гаять зур киңлегенә күз күреме дә җитәрлек түгел. Безнең үз машиналарыбыз, кырларны сугару өчен безнең үз корылмаларыбыз бар. Барсы да үзебезнеке! Элекке заманда изелгән халык болар турында башына да китерә алмый иде.

Валериан Таҗикстанның үсеше турында да бик күп сөйләде. Һәм ул өлкәнең һәм Күкчәтау шәһәренең ничек үзгәргәнлеген яхшылап карау өчен отпуск вакытында туган җиренә — Казахстанга кайтырга уйлавын сөйләде.

Елена Куйбышева.

Москва өлкәсенең яш тамашачылар театры А. Яковлевнең „Пионер Павел Морозов“ исемле пьесасын сәхнәгә куярга хәзерләде. РӘСЕМДӘ: Пьесаның беренче пәрдәсеннән бер күренеш. А. Гусев фотосы. (ТАСС фото-клишесе).

Буяучы абый

Безгә бер абый килде,
Өйгә туп-туры керде.
Киемнәре буялган.
Кулына пумала алган.

Бездә калган ни эше?
Нигә килгән бу кеше?
Кызык итеп көлдем мин:
— Шапшак абый, — дидем мин.

Әти-әни тордылар,
Аңа каршы бардылар,
Күрештеләр кул биреп:
— Буяучы килгән,—диеп.

Ә ул абый күз кысты,
Миңа карап сүз кушты:
— Сиңа килдем мин, батыр,
Бүлмәң булсын дип матур.

Мин артык эндәшмәдем:
— Кирәкми, — дип әйтмәдем.
— Эшкә башлыйк, — диделәр
Һәм бүлмәгә керделәр.

Өстәлне, кроватьне,
Уенчык этне, атны...
Барсын-барсын алдылар,
Өйдән үк чыгардылар.

Мин түзмәдем, җыладым,
Әниемнән сорадым:
— Абый ник өйгә узды?
Уенымны килеп бозды...

Әни дәште елмаеп:
(Ә мин торам моңаеп)
— Ул, абый уңган кеше,
Бүлмәләр буяу — эше.

Мин тагын да җыладым:
— Инде бүлмәсез калдым.
Бүлмәм чүп белән тулыр,
Киеме кебек булыр...

Әни әйтә: „җылама,
Киеменә карама.
Бөтен җире ялт итәр,
Үзеңнең исең китәр...“

* * *

Озак урамда йөрдем,
Аннан өйгә йөгердем.
Әни әйтә: „Чәй булды,
Инде сәгат бер тулды.

Бүлмәңне кереп кара,
Анда эш бетеп бара...“
Керсәм бүлмә ялт итә,
Аптырыйм, исем китә...

Түшәм матур төс алган,
Ишек ялтырап калган.
Стенада чәчәкләр,
Якты нурлар чәчәләр.

Мин көләм, әй шатланам,
Әйтерсең, канатланам,
Буяучыны хөрмәтлим:
— Рәхмәт, абый, рәхмәт, — дим.

Алмалар бирдем аңа:
— Яратам, — дидем аңа.
— Буяучы абый, көзгә
Тагын зинһар кил безгә.

Ж. Тәрҗеманов

А. П. Чехов

Антон Павлович Чехов рус әдәбиятының якты йолдызларыннан берсе. Ул кыска хикәяләр мастеры, әдәби тел остасы булып танылган язучы.

Чехов тудырган җәүһәрләр мәңге югалмаячаклар. Аның әсәрләре иске тормышның гарип, коточкыч дәһшәтле якларын безнең күз алдыбызга китереп бастыралар. Без аның әсәрләрен укып, ләгнәтләнгән искелек белән танышабыз. Безнең бәхетле тормышыбызның гүзәллеге тагын да ачыграк күренә.

Чеховның тууына быел 80 ел тулды. Шул уңай белән без журналыбызда аның „Ванька“ исемле хикәясен урнаштырабыз.

ВАНЬКА

Моннан өч ай элек итекче Аляхинга өйрәнчеккә бирелгән тугыз яшьлек малай—Ванька Жуков рождество алдындагы төндә йокларга ятмады. Хуҗаларның һәм ярдәмче мастерларның иртәнге гыйбадәткә китүләрән көтеп алды да, хуҗаның шкафыннан кара салынган кечкенә шешә, күгәргән каләмле ручка табып алды һәм таушалып беткән кәгазне алдына җәеп куеп, яза башлады.

Беренче хәрефне язар алдыннан, ул берничә тапкыр куркынып ишекләргә һәм тәрәзәләргә каранды. Ике ягыннан да аяк киеме калыплары куелган шүрлекләр арасына урнаштырылган тоныкиконага кырын гына күз төшерде, һәм көрсенеп авыр сулады. Скамья өстендә кәгаз ята, ә ул үзе скамья алдында тезләнеп тора.

„Сөекле бабам, Константин Макарыч!—дип язды ул. — Сиңа хат язам. Сезне рождество белән котлыйм һәм сиңа аллаһетагаләдән бөтен яхшылыкны телим. Минем атам да, әнкәм дә юк, тик бер син генә калдың“.

Ванька күзләрен шәмнең шәүләсе җемелдәгән караңгы тәрәзәгә төшерде, һәм Живаревлар дигән байларда төнге сакчы булып хезмәт итүче үзенең бабасы Константин Макарычны тиз генә күз алдына китерде. Бу кечкенә, ябык, ләкин гадәттә булмаганча тере һәм җитез, алтмыш биш яшьләрдәге, һәр вакыт көлеп тора торган йөзле һәм исерек күзле бер карт иде.

Көндез ул хезмәтчеләр тора торган йорттагы кухнядә йоклый яки кухарькалар белән гәпләшә, төнлә инде, киң толыпка уралып, утар буйлап йөри һәм үзенең шакылдавыгын шакылдата. Аның артыннан карт Каштанка һәм үзенең кара төсе һәм ләтчәнекедәй озын гәүдәсе өчен Вьюн дип аталган ата эт башларын иеп атлап йөриләр.

Бу Вьюн гадәттән тыш ихтирамлы һәм ягымлы, үз кешеләренә дә, чит кешеләргә дә бер үк төсле ялагайланып карый, ләкин ышаныч белән файдаланмый. Аның ихтирамлылыгы һәм юашлыгы астында нак иезуит[1] усаллыгы яшеренгән. Берәү дә аннан остарак итеп, вакытында посып кына килеп аяктан каптырып алырга, базга төшәргә, яки мужикның тавыгын урларга булдыра алмый. Инде берничә тапкыр аның арт аякларын сындырдылар, бер-ике тапкыр асып куйдылар, һәр атна саен үтергәнче кыйнап тордылар, ләкин ул һәр вакыт савыга иде.

Бабай хәзер, капка янында торадыр,

[1] *Иезуит — ике йөзле һәм мәкерле кеше, үзенең максатына ирешү өчен һәр төрле пычраклыклар эшләүдән тартынмаучы.*

авыл чиркәвенең кып-кызыл тәрәзәләренә күзләрен йөртәдер һәм, киез итекләре белән таптанып, йорт кешеләре белән гәпләшә торгандыр. Аның шакылдавыгы билбавына бәйләнгән. Ул кулларын чайкалдыра, салкыннан бөрешә һәм картларча хихылдап, әле асырау кызны, әле кухарьканы чеметә.

Хатыннарга үзенең тәмәке савытын сузып:

— Тәмәке иснәп карыйсызмы әллә?— ди ул.

Хатыннар исниләр һәм төчкерәләр. Карт әйтеп бетерә алмаслык куана, шат көлү белән җәелеп көлә һәм кычкыра:

— Кубарып ал, туңган!

Этләргә дә тәмәке иснәтәләр. Каштанка төчкерә, танавын чайкый һәм үпкәләп, читкә китә. Вьюн инде әдәплелек саклап, төчкерми һәм коерыгын гына болгый.

Ә тышта һава искиткеч әйбәт. Һава тын, үтә күренмәле һәм саф. Төн караңгы, ләкин өйләрнең ак түбәләре һәм морҗалардан чыгып күтәрелгән төтеннәре, бәстән көмешләнгән агачлары, көртләре белән бөтен авыл күренеп тора. Бөтен күк йөзе шат җемелдәүче йолдызлар белән тулган, һәм Киек каз юлы шундый ачык булып күренә ки, әйтерсең, аны бәйрәм алдыннан юганнар һәм кар белән ышкыганнар...



„Сөекле бабам, Константин Макарыч!“— дип язды ул.

Ванька авыр сулады, каләмен карага манды да язуында дәвам итте:

„Ә кичә мине кыйнадылар. Балаларын бишектә тирбәткәндә ялгыш йоклап китүем өчен, хуҗа мине чәчемнән өстерәп ишек алдына чыгарды һәм каеш белән ярды. Ә шушы атнада хуҗа хатыны миңа селедка әрчергә кушты, ә мин койрыгыннан әрчи башладым, ә ул селедканы алды да, балык башы белән минем авыз-борныма төрткәләде. Ярдәмче мастерлар миннән мыскыллап көләләр, аракы алырга кабакка җибәрәләр, хуҗаларның кыярларын урларга кушалар, ә хуҗа нәрсә эләксә, шуның белән кыйный. Ә ашарга бер нәрсә юк. Иртә белән икмәк, көндезге ашка бутка һәм кичкә тагын икмәк бирәләр, ә чәй яки шулпаны хуҗалар үзләре генә шупырдаталар. Миңа өй алдында йокларга кушалар, ә инде аларның балалары җыласа, мин бөтенләй йокламыйм, бишек тирбәтәм. Сөекле бабам, алла мәрхәмәтен ит, ал мине моннан өйгә, авылга, минем һичбер түзәрлегем калмады... Синең аякларыңа егылам һәм мәңге аллага ялварырмын, алып кит мине моннан, ә юк исә үләм“...

Ванька авызын кыйшайтты, үзенең керле йодрыгы белән күзен сөртте һәм сулыгып-сулыгып көрсенде.

„Мин сиңа тәмәке уармын,—дип дәвам итте ул, — гыйбадәт кылырмын, әгәр берәр начарлык эшләсәм, Сидор кәҗәсен кыйнаган шикелле, кыйнарсың мине. Әгәр дә миңа эшләрлек урын булмас дип уйласаң, мин ходай хакына ялынып приказчиктан итекләр чистартырга алуын сорармын, я булмаса Федька урнына көтүче малай булып барырмын. Сөекле бабам, бер нинди мөмкинлек юк, бары бер үлем генә. Җәяүләп авылга качмакчы идем, итекләрем юк шул, суыктан куркам. Ә инде зур үскәч, моның өчен үзем сине туендырырмын һәм берәүгә дә сине рәнҗе-

тергә ирек бирмәм, ә үлсәң, әнием Пелагиягә дога кылган шикелле үк, дога кылырмын“.

„Ә Москва зур шәһәр. Йортлар барсы да байларныкы, атлар да күп, ә сарыклар юк, этләр дә усал түгел. Биредә балалар йолдыз күтәреп йөрмиләр һәм чиркәүгә беркемне дә җырларга җибәрмиләр, ә бер тапкыр мин бер кибеттә, тәрәзә алдында җепләре һәм калкавычлары белән үк һәм теләсә нинди балыкка ярый торган кармаклар сатылганын күрдем, алыр өчен бик шәпләр, хәтта бер потлы җаенгә дә чыдарлык бер кармак бар. Аннан кайбер кибетләрдә һәр төрле, бариннар манерындагы мылтыклар сатылганны күрдем, небось, һәрберсе йөз сум торадыр... Ә ит кибетләрендә көртлекләр дә, кыр тавыклары да, куяннар да бар, ә аларны кайсы урында атып алулары турында кибетчеләр әйтмиләр.

„Сөекле бабам, ә хуҗаларда күчтәнәчләр белән елка булса, миңа алтынланган чикләвек ал да, яшел сандыкка яшереп куй.

Ольга Игнатьевна ападан сора, Ванька өчен диген“.

Ванька калтыранып сулады һәм тагын тәрәзәгә төбәлде. Ул хуҗаларга елка алып кайтыр өчен, урманга һәр вакыт бабасының баруын һәм Ванькане да үзе белән бергә алып баруын хәтерләде. Күңелле иде ул чакта! Бабасы да тамак кыра, суык та тамак кыра, ә аларга карап, Ванька да тамак кыра. Шулай була торган иде: әле елканы кисеп алганга кадәр, бабасы трубка тарта, озак итеп тәмәке исни, туңган Ванюшкадан көлә... Бәс белән капланган яш елкалар селкенмичә торалар, һәм арабыздан кайсыбызга үлем килеп җитте икән дип көтәләр. Кая гына килеп тотынма, көртләр буенча куян уктай оча... Карт кычкырмыйча булдыра алмый:

—Тот, тот... тот! Ах, койрыксыз шәйтан! Бабасы кисеп алынган елканы хуҗалар йортына өстерәп кайта, ә анда елканы чистартырга тотыналар... Барсыннан да бигрәк Ванька яраткан Ольга Игнатьевна тырышып йөри. Әле Ванькаcның анасы Пелагия исән вакытта, хуҗаларда асрау булып хезмәт иткәндә, Ольга Игнатьевна Ванькане тәмле нәрсәләр белән сыйлый иде һәм ул эш юктан эш булсын дип, аны укырга, язарга, йөзгә кадәр санарга һәм хәтта кадрил биергә дә өйрәтте. Инде Пелагия үлгәч, ятим Ванькане хезмәтчеләр тора торган өйдәге кухнягә бабасына, ә кухнядән Москвага итекче Аляхингә озаттылар...

„Кил, сөекле бабам,—дип дәвам итте Ванька: сиңа ялварам алла хакы өчен, ал мине моннан. Кызган син мине, бәхетсез ятимне, юкса мине һәр вакыт тукмаклап торалар һәм өзелеп ашисы да килә, ә шундый күңелсезлек, сөйләргә дә мөмкин түгел, һәр вакыт җылыйм. Ә бер көнне хуҗа калып белән башыма шундый каты итеп сукты, егылдым һәм көчкә аңыма килдем. Харап минем тормышым, теләсә нинди эт көненнән дә начар... Ә тагын Аленага, сыңар күзле Егоркага һәм кучерга сәлам күндерәм, ә минем гармонымны бер кемгә дә бирмә. Синең баланң булып калучы Иван Жуков, сөекле, бабам, кил“.

Ванька язылган кәгазне дүрткә бөкләде һәм кичә генә бер тиенгә сатып алынган конвертка тыкты... Азрак уйлап торганнан соң, ул каләмен карага манды да адрес язды:

АВЫЛГА БАБАЙГА

Аннан соң бераз кашынып алды, уйлап торды да өстәде: „Константин Макарычка“. Язарга комачаулык итмәүләренә куанып, ул бүреген киде һәм тун сәләмәсен өстенә салмыйча гына, күлмәкчән генә урамга чабып чыкты...

Ит кибетендәге сатучылар, кичә ул алардан сорагач, хатларның почта ящикләренә салынуларын, ә ящикләрдән исерек ямщикләр токкан һәм яңгыравыклы кыңгыраулар тагылган почта атларында бөтен җиргә таратылуларын сөйләгәннәр иде. Ванька беренче почта ящигенә йөгереп барып җитте һәм кыйммәтле хатны ящикнең ярыгына салып җибәрде...

Тәмле өметләр белән юанып, бер сәгат үткәч, ул каты йокыга талды... Төшендә ул пич күрде. Пич башында ялан аякларын салындырып бабасы утыра һәм хезмәтче хатыннарга хат укый... Пич тирәли Вьюн йөри һәм койрыгын болгый.

Россияне уятучы көчле набат

(Герценнең туына 70 ел тулу уңае белән)

Ике малай кулга-кул тотынышып, агачлар арасындагы сукмактан югары күтәреләләр. Тауны менгән саен аларның күз алларында төрле матур күрнешләр киңрәк булып ачыла бара.

Әнә анда, түбәндә, Москва елгасы ялтырап, борыла-сырыла агып ята. Әнә анда, чиркәүләренең алтын гөмбәзләре, биек йортлары белән Москва шәһәре күренә...

Ә малайлар һаман югары күтәреләләр. Менә алар тау башына да менеп җиттеләр. Һәм бер-берсен кочаклаган килеш, карт шәһәргә бик озак карап тордылар. Тирә-якны нурга күмеп, таулар артына яшеренергә теләгән кояшның соңгы нурлары астында бу ике дус ант иттеләр. Алар кешелек бәхте өчен, хаклык өчен булган көрәштә үзләренең тормышларын да кызганмаска сүз бирделәр.

Бу ике дус: 16 яшьлек Александр Герцен белән 15 яшьлек Николай Огарев иде. 1828 нче елда, Москва шәһәре янында, бу ике дусның бер-беренә чын күңелдән сүз бирүләре „Воробьев тавындагы ант" исеме астында тарихка кереп калды.

Александр Иванович Герцен 1812 нче елның 6 нчы апрелендә туа.

Ирек сөюче Шиллер поэзиясен Герцен белән Огарев бик яратып укыйлар. 1825 нче елда декабристларны вәхшиләрчә үтерү Герцен белән Огаревка бик нык тәэсир итә.

1829 нчы елда Герцен Москва университетына укырга керә. Ул биредә дә үзенең дусты Огаревны һәм үзенең фикерләрен яклаучы байтак кешеләрне очрата. Огарев белән бергә ул яшрен түгәрәк оештыра. Түгәрәк членнары философия, политика мәсьәләләре белән бик кызыксыналар.

„Җәмгыять өчен куркынычлы" фикерләр таратулары өчен, 1834 нче елда, Герцен белән Огарев икесе дә кулга алыналар. Герцен төрмәдә 10 ай утырганнан соң Пермь шәһәренә сөрелә, аннан Вяткага җибәрелә. Шунда ул 3 ел чамасы сөргендә яши.

Алты еллар сөрелеп йөргәннән соң, Герцен 1840 нчы елда Москвага кайта, ләкин бер ел да узмый, жандармнар шефы Бенкендорф аны үзенә чакырта һәм:



— Хөкүмәт өчен зарарлы фикерләр таратуыгыз турындагы мәгълүматлар патша хәзрәтенең колагына да килеп ирешәте,—дип допрос ала башлый. Бу сөйләшүләргә берничә көн үткәч, Герценне яңадан сөргенгә—Владимирга җибәрәләр.

Бу вакыт турында Герцен: „Без яши торган чор Россия өчен куркыныччы!"— дип язды. Владимирда сөргендә вактында Герцен беренче романын язарга керешә. Бу романында ул үзе иң күп уйлый торган нәрсә турында—талантларның вакытсыз һәлак булуына кемнең гаепле икәнлеге турында язды. Ул бу романын „Кем гаепле?"—дип атады.

Герценне эзәрлекләү һаман дәвам итте, ул инде „Еракка, еракка китәргә кирәк, озакка китәргә кирәк!"— дип үз-үзенә карар биреп куйды. Чит ил паспорты алу артыннан Герцен дүрт ел буе йөрде, тик 1847 нче елда гына ул Парижга китә алды.

Герцен буржуазияне дошман күрә иде. Ул акча, байлык җыюга омтылучыларны хурлады. Ул буржуаз җәмгыяттә булган түбән могамәләләрне, алдауны, буржуазиянең ялганын һәр вакыт ача килде. Ул: „Буржуазия кешеләрне сөюдән аера, алар арасында җансызлык һәм салкынлык чәчә. Иң яхшы кешелек хисләрен франкларга алмаштыра“,—диде.

Герцен чит илдә үзенең ирек сөючән фикерләрен киңрәк җәеп җибәрергә мөмкинлек тапкач, патша хөкүмәте аңа Россиягә кайтырга кушты. Герцен монардан баш тарткач, 1851 нче елның көзендә, 1 нче Николай дәүләт советының Герцен турындагы карарын раслап: „Бу гаепләнүчене, сенат хөкеме буенча, бөтен мөлкәтен алып, дәүләт җиреннән бөтенләйгә куылган дип санарга!“—дип язды.

1852 нче елда Герцен „Булганнар һәм уйлар“ исемле әсәрен яза башлады. Ул бу әсәрендә хөкүмәтнең, башында патша торган эре монархистик бюрократиянең кабахәтлекләрен, оятсызлыкларын һәм наданлыкларын фаш итте.

1853 нче елда Лондонда Герцен „ирекле рус типографиясе“ оештырды. Ул анда елда бер тапкыр чыга торган „Полярная звезда“ ны (1855—1869) һәм „Колокол“ны (1857—1867) чыгара башлады.

„Колокол“ крепостнойлыкны, самодержавиене рәхимсез рәвештә тәнкыйтьләде, крестьяннарне азат итүне һәм азчылык милләтләргә азатлык бирүне таләп итте.

„О, әгәр дә минем сүзләрем сиңа җитсәләр иде,—дип язды Герцен,—рус җиренең хезмәт иясе һәм газап чигүчесе. Син алпавытны дошман күрәсең, алардан куркасың һәм син бик хаклы... Патша алар белән һәм алар аныкы...“

Герцен 1870 нче елда чит илдә үлде.

Герцен ялкынлы патриот иде, үз ватанын, үз халкын сөйде. Герценнең исме русның бөек революцион фикер ияләреннән һәм патриотларыннан: Белинский, Чернышевский, Добролюбовларның исемнәре белән янәшә тора.

Владимир Ильич Ленин Герценгә һәр вакыт зур бәя бирде. Тормышының азагына таба Герцен „Үзенең карашын... Интернационалга, Маркс җитәкчелек иткән Интернационалга, пролетариатның „полкларын җыя“... „эшчеләр дөньясын“ берләштерә башлаган Интернационалга юнәлдерде“,—дип язды Ленин.

Совет халкы Герценне үткән заманның иң яхшы кешеләренең берсе итеп хөрмәтли. Герцен үз халкын, үзенең ватанын бик нык сөя иде.

Герцен үзенең кайнап торган дәртен, энергиясен, азатлык турындагы тирән философик фикерләрен, публицист һәм язучы буларак үзенең көчле каләмен дә халыкларны патша изүеннән коткару өчен көрәшкә, әнә шул бөек эшкә багышлады.

Бишек җыры

Тыныч йокла, әй былбылым,
Куанычым син.
Күз нурым син, сандугачым,
Юанычым син.

Тыныч, рәхәт үсеп җитәр,
Улым булыр дәү,
Йокла, йокла, йом күзләрең,
Әлли-бәлли, бәү.

Карт мин, ләкин сиңа бүген
Әкият сөйләмим.
Безгә җырланган җырларны
Сиңа көйләмим.

Җырлыйм сиңа, сөеклем, сез
Үсәсез күбәү.
Тыныч йокла, йом күзләрең,
Әлли-бәлли, бәү.

Корыч канатларың җәеп,
Улым, очарсың.
Герой булгач Сталинның
Үзен кочарсың.

Күкрәгеңдә орден балкыр
Үсеп булгач дәү.
Әй шаяным, йом күзләрең,
Әлли-бәлли, бәү.

Фәез Хәбибуллин.

Астрахань шәһәре.



АРКТИКА БАТЫРЛАРЫ

Очсыз-кырыйсыз Боз океаны. „Георгий Седов“, „Малыгин“ һәм „Садко“ бозваткычлары тау-тау булып йөрүче бозларга каршы озак һәм нык көрәштеләр. Һәм, ниһаят, 1937 елның 23 нче октябреннән 24 нче октябренә каршы төндә алар Новосибирск атауларыннан 30 миль көнбатыштарак булган урында кышлау өчен тукталырга мәҗбүр булдылар. „Седов“ның героик хәрәкәте менә шулай башланды. Авыр һәм үтеп чыга алмаслык бозлар „Седов“ны төрле яклап кыстылар. Алар карабка куркыныч тудырдылар, аның тирәсендә үкереп, шаулап йөзделәр.

Иптәш Сталинның заданиесе буенча 1938 нче елның 26 нчы февралендә кышлаучы бозваткычлар янына 3 зур самолеттан торган һава экспедициясе җибәрелде. Бу самолетларны советның иң яхшы очучылары—Советлар Союзы Геройлары Алексеев, Головин иптәшләр һәм котып очучысы орденлы иптәш Орлов алып бардылар. Һава экспедициясе апрель аенда 184 кешене, шул исәптән „Седов“ның ауру капитаны иптәш Швецовны да, Зур Җиргә алып чыкты. Судноларда кышларга иң тәҗрибәле моряклар гына һәм гыйлми работниклар гына калдылар.

„Седов“ командирсыз калды. Ләкин ул тиз табылды. Бозваткычта калган кешеләр барсы да бер юлы Константин Бадигинга карадылар:

— Ул капитан булырга тиеш.

Ауру Швецов та:

— Бадигин капитан булырга тиеш,— диде.

Шулай итеп, Константин Сергеевич Бадигин „Седов“ның капитаны булып эшли башлады.

Бу 1938 нче елның августында булды.

Бу көннәрдә бозваткычка 28 яшь тулды. Капитан Бадигинга да шул ук көннәрдә 28 яшь тулды.

Константин Бадигин Пенза шәһәрендә туган. Анда, билгеле, диңгезләр юк. Диңгездә, ерак океаннарда йөзү турында балачагында ул барыннан да азрак уйлады. Тугыз еллык мәктәпне тәмам иткәннән соң, Бадигин Москвада штукатурчы булып эшли. Яшь штукатурчыны Ленинградка, Фрунзе исемендәге Хәрби-Диңгез Училищесенә укырга җибәрәләр. Семья шартлары аркасында Бадигин бередән китә һәм нинди дә булса бер суднода матрос булырга карар бирә.

Владивостокка барып, „Индигирка“ пароходында 2 нче категорияле матрос булып эшкә керешә. Күп кенә судноларда йөри һәм өйрәнә. Константин дөньяның барлык портларын күрә. Владивостокка кайтканнан соң, диңгез техникумында имтихан бирә—ел ярым эчендә 4 еллык курсны бик яхшы үзләштерә.

Шуннан соң Бадигин төньякка, Архангельскига килә. Башта урман ташучы суднода эшли. Комсомол Үзәк Комитеты „Красин“ бозваткычында комсомолецлар экипажы төзегәч, капитанның өченче ярдәмчесе булып, аңа күчә. 1937 нче елның 5 нче февралендә „Седов“ капитанының икенче ярдәмчесе була, ә августтан башлап хәрәкәтнең иң авыр көннәрендә, Бадигин „Седов“ның капитаны була.

Менә ул—безнең чорның яшь кешесе! Константин Бадигин һәм аның 14 иптәше боз таулары арасында, зәһәр суыкта батырларча эшләделәр. Чөнки седовчылар барсы да белемле, чыныккан, хезмәт сөючән, нык торучан, куркусыз кешеләр. Алар барсы да Ватаныбызга һәм бөек Сталинга чиксез бирелгән кешеләр.

1938 нче елның язы һәм җәе судноларның хәлен җиңеләйтә алмады. Өч карабның өчесе дә боз арасында туңып калдылар һәм үзлекләреннән хәрәкәт итә алмадылар. Шул ук елның августында „Ермак“ бозваткычы Лаптевлар диңгезенә чыкты. Бу куәтле караб бозларны ярып, карван янына таба 10 көн буена хәрәкәт итте. Ул 28 нче августта, таң алдыннан, кышлаудагы караблар янына якын ук килеп җитте, һәм ул „Малыгин“ белән „Садко“ ны бозлар арасыннан чыгарды. Ә „Седов“ барсыннан да ерактарак торганга күрә һәм үзлегеннән, хәтта караб артыннан да, хәрәкәт итә алмаганга күрә, аны бозлар арасыннан чыгару мөмкин булмады.

Ватаныбызның 15 батыр улы, үз капитаннары Бадигин белән бергә „Седов“ның палубасына чыгып бастылар һәм китеп баручы карванга бик озак кул болгадылар...

Бу героик хәрәкәтнең беренче көннәреннән үк „Седов“та гыйлми эш бер генә сәгаткә дә тукталып тормады. Седовчылар Үзәк Котып бассейненең тормышын өйрәнделәр. Советның яшь 15 патриоты Ватан өчен, совет халкының даны өчен үзләренең тарихи батырлыкларын күрсәттеләр. Бозваткычны һәм үзләрен сакларга алар һәр вакыт хәзер тордылар.

Менә шундый бер хәл булды:

1938 нче елның 26 нчы сентябре иде. Тирә-юндәге бозларның көчле ударлары нәтиҗәсендә, судно кич сәгат 11 дә кинәт чайкалып китте һәм уң як бортка янтая башлады. Машиналар бүлегенә су керә. Карабта аврал игълан ителде. Иң кыен моментта, котылырга һичбер ышаныч калмады инде дигән вакытта, механик Токарев һәм машинист Шарыпов карабның тишелгән урнын эзләп таптылар. Билләренә кадәр җиткән бозлы су эчендә эшләп, тишелгән урынны бу батыр кешеләр бик тиз ямап куйдылар һәм караб коткарылды.

1938 нче елның 24 нче октябрендә „Седов“ның героик хәрәкәтенә бер ел тулды. Бу көндә Москвадан Сталин һәм Молотов иптәшләрдән экипажга котлау телеграммасы алынды. Батыр котыпчылар үз эшләренә яңа көч белән керештеләр. Бөек ышаныч белән, партиянең һәм хөкүмәтнең кайгыртучанлыгы белән рухланган седовчылар Ватаныбыз өчен үз-үзләрен аямыйча эшләделәр. Алар 1939 нчы елның беренче маена кадәр судноның булган урынарын билгеләп, 335 астрономия күзәтүләре һәм 2.100 метеорология күзәтүләре үткәрделәр.

Караб август аенда хәрәкәтнең иң төньяк ноктасына—төньяк киңлекнең 86 градус 39,5 минутына килеп җитте. Бу зур җиңү иде! Котыпны тикшерену-өйрәнү тарихында иң беренче тапкыр буларак, седовчылар гади карабта әнә шундый ераклыкка бара алдылар!

Хәрәкәтнең икенче еллыгы седовчыларны Шпицберген киңлеге тирәсендә очратты. Аларны биредә яңа шатлык каршылады: экипаж 1939 нчы елның 24 нче октябрендә Сталин һәм Молотов иптәшләрдән икенче тапкыр котлау телеграммасы алды.

Ә тиздән, 7 нче ноябрьдә, седовчылар Бөек Октябрь Социалистик Революциясенең XXII еллыгын тантаналы рәвештә бәйрәм иттеләр. Бу көндә алар боз өстенә чыктылар. 15 батыр барсы да факеллар яктысы астында сафка төзелделәр, кызыл байракны югары күтәрде-

ләр һәм җырлый-җырлый боз тавына бардылар. Константин Сергеевич аларның барсын да бөек бәйрәм белән котлады. Биек боз тавы өстендә большевиклар партиясе хөрмәтенә, Сталин хөрмәтенә көчле, бердәм „ура!“ тавышлары яңгырады.

...Ә шуннан соң бер ай үтүгә, илебезнең иң куәтле бозваткычы, Арктика флотының флагманы „Иосиф Сталин“ бозваткычы, „Седов“ны алып кайту өчен Гренландия диңгезе бозларына чыгып китте. Тарихта тиңдәше булмаган бу поход экспедиция начальнигы Советлар Союзы Герое Папанин һәм данлыклы капитан Белоусов иптәшләр җитәкчелегендә уңышлы рәвештә тәгәлләнде.

„Седов“ның хәрәкәтен Ватаныбыз зур игтибар белән күзәтте. Зурлар белән бергә үк, балалар да моның белән кызыксындылар, аны өйрәнделәр. Седовчылар кебек батыр булу—бу һәрбер яш кешенең хиялы.

* * *

Кыю кеше—русның котыпны тикшеренүчесе лейтенант Георгий Седов моннан 26 ел элек Арктика бозлары арасында һәлак булган иде.

Бөек Сталин рухландырган кешеләр—советның батыр кешеләре—26 ел вакыт үткәннән соң, „Седов“ның хиялын тормышка ашырдылар. Алар бу батырның—төньяк котыпчының исмен йөртүче карабта гигант юл үттеләр һәм төньяк котыпны җиңделәр. Төньяк Боз океанының боз киңлекләре арасында йөзеп, көнчыгыштан көнбатышка таба өч мең миль чамасы юл үттеләр.

Легендар „Г. Седов“ бозваткычының экипаже үз өстенә йөкләнгән бурычны гүзәл үтәде. Седовчылар Арктиканы җиңү тарихына яңа сәхифә яздылар, алдынгы фәнне тагын да баеттылар.

Геройларга мактау һәм дан!

Нальчик шәһәрендәге (Кабардино-Балкар АССР) пионерлар дворецы каршындагы тегү-чигү түгәрәге яхшы эшли. РӘСЕМДӘ: пионерка Валя Мисакова үзенең эшен түгәрәк җитәкчесе Т. Сверловага (уң якта) күрсәтә. **Г. Смоль** фотосы. (ТАСС фото-клишесе).

ОНТЫЛМАС КОМЕДИЯ АВТОРЫ

Александр Сергеевич Грибоедов рус халкының классик язучысы. Ул рус әдәбияте тарихына үзенең мәңге онтылмас комедиясе „Горе от ума“ белән керде. Бу атаклы комедия тарихта әһәмияте зур булган декабристларның көрәш еллары белән таныштыра. Шуның белән бергә, Грибоедов бу комедиясендә үзенең строе мәңге яшәр дип уйлаган иске дворян җәмгыятен һәм аның Фамусов кебек комсыз, тупас, надан вәкилләрен күрсәтә һәм аларны рәхимсез рәвештә тәнкыйть итә. Фамусовлар тормыш һаман да үзләре теләгәнчә булыр, дип уйлыйлар, ләкин шул вакыт тормыш сәхнәсенә яңа, Фамусов кебек соры кортлар өчен куркыныч фикерләр белән Чацкий килеп баса. Һәм Чацкийлар крепостник стройның үлеме турындагы хәбәрне китерәләр.



„Горе от ума“ комедиясе рус сәхнәсендә йөз елдан артык төшми уйналып килә һәм хәзерге көндә дә ул бөек поэтик бер әсәр булып тора. Бу комедиядә Грибоедов боярлар Москвасын һәм аның Фамусов, Сколозуб, Хлестова, Тугоцовский кебек ике йөзле, тупас, комсыз, кеше җилкәсендә яшәүчеләрне ачык рәвештә күрсәтә. Алай гына да түгел, бөек шагыйрь үзенең комедиясендә бу кешеләрне хөкем итә. Менә шуңа күрә дә „Горе от ума“ комедиясе ул вакытта басып чыгарылмый. Патша цензурасы әсәрне бастырып таратуны тыйса да, ул күчерелеп кулдан кулга тарала. Декабристлар бу комедияне үзләренең политик агитацияләре өчен кулланалар. Әсәр 1824 нче елда язылган булса да, фәкат 1862 нче елда гына, реформадан соң гына, тулы килеш басылып чыга.

Грибоедов декабристлар белән дус һәм фикердәш була. Петербургка килгәч, ул Одоевский, Рылеев, Бестужев кебек декабристлар белән таныша. Кавказда яшәгәндә дә ул декабристларның яшрен оешмасы вәкилләре белән очраша. Шушы эшләре өчен ул 1826 нчы елда кулга алына һәм Петербургка җибәрелә. Ләкин ул үзенең декабристлар оешмасында торуын инкар итә һәм соңыннан ябылудан азат ителә.

Александр Сергеевич Грибоедов үзе борынгы дворян нәселеннән. Ул 1795 нче елда Москвада туа. Грибоедов зур белемле, культуралы язучы була. 7—8 яшендә ул Москва университеты пансионына керә, 11 яшендә инде ул университет студенты булып хисаплана. Университетның философия һәм юридик факультетында укый. Укуын тәмамлагач, шул ук университетта укытучы булып кала. Ләкин 1812 нче елгы сугыш башлангач, ул сугышка китә. Хәрби хезмәттән соң, Петербургта Чит Ил Эшләре коллегиясендә эшли. Бу вакыт ул театр, әдәбият эшләре белән бик кызыксына һәм кыска-кыска гына комедияләр һәм водевильләр яза башлый.

Ул соңыннан Иранда рус дипломатик миссиясендә секретарь булып эшли. Үзенә йөкләнгән эшне яхшы үтәве сәбәпле, Грибоедов Россиянең Ирандагы посолы булып билгеләнә.

1829 нчы елның 30 нчы январенда, чуалыш вакытында кораллы бер төркем рус посольство бинасын чолгап ала. Бинага ут төртелә. Посольстводагы бөтен кеше үтерелә. Мальцев фамилияле бер генә кеше исән кала.

Менә шулай итеп атаклы шагыйрь Грибоедов та вакытсыз һәлак була. Патша самодержавиесе талантлы язучыга иркенләп иҗад итәргә мөмкинлек бирми, аңа иң куркынычлы, иң авыр эшләрне йөкли. Һәм шулай итеп, самодержавие үзенә куркынычлы булган яңа фикерле бу язучыдан да котылу юлын таба. Бик күп талантлар кебек үк, Грибоедов та вакытсыз югала.

А. Әхмәт.

Катокта



Шаулап тора бозлык өсте,
Бозлык зәңгәр—күзгә төсле.
Менә шунда яш балалар
Шуып, уйнап ял алалар.
Әкрен генә җилләр исә,
Җилгә уйнап ак кар төшә;
Шундый матур! Шат күңлебез,—
Күңелле үтә һәр көнебез.

Н. Хәмидуллин.

***

Конькиларын такканнар да, кышкы бозда
Укучылар берсен-берсе уза-уза,
Шуып йөри, коштай очып кызып-кызып,
Бөтерелеп, төрле эзләр сыза-сыза.
Ялкынланып балкый шатлык яш йөрәктән,
Спорт белән чыныга бездә үсмер тән,
Һәм җырлыйлар көр күңелләр—шиңмәс гөлләр.
„Ил каршында таза, матур булып үсәм“.

В. Гобәйдуллин.

Җаваплы редактор **Г. ХӘБИБУЛЛИН.**

Ответств. редактор **Г. ХАБИБУЛЛИН.**

Заказ № 501. 2 табак. Табакта 70.700 знак. Главлит вәкиле № 876. Производствога бирелде 21/I—40 ел. Басарга кул куелды 4/II — 40 ел. Тираж 8039. Кәгаз форматы 70×108.

Александров исемендәге типография. Казан, Бауман урамы, 19. 1940.

КҮҢЕЛЛЕ ЯЛ

Географик башваткыч

Укучылар каникулны шатланып каршы алдылар. Чөнки укулар башланганга (Сибирьдәге тау) вакыт (СССР ның Европа өлешендәге шәһәр) бит инде. Шунлыктан алар ачык һавада иркенләп уйнауны бик сагынганнар.

Роза көн дә иртүк тора да башына (Тувин халык республикасының башкаласы) төстәге (Америкадагы диңгез каналы) киеп, аягына чаңгысын әләктерә дә (Латвиянең башкаласы) янындагы тауга китә. Һәм иптәшләре белән ял көннәрен күңелле үткәрә. Түбәннән (Казахстандагы ташкүмер учагы) бу тау артык биек түгел, ләкин менә башлагач бик тиз арыйсың.

Әле кичә генә (ибирьдәге зур елга), шул таудан шуганда аягы таеп, түбәнгә таба тәгәрәп төшеп китте. (Африкадагы зур өлкә) кайтучы кызлар, бу хәлне күреп, эчләре катканчы көлделәр. (Сибирьдәге шул ук елга) бөтенләй карга буялып бетте. Аның битләре ут кебек булып (Сибирьдәге бер елга) иде. Ул урыннан торып кагынды да, иптәшләре (Ока елгасы буендагы шәһәр) һәм (Казахстандагы күл) белән тагын тауга менеп китте.

⁂

Бу географик башваткычтагы җәя эчендә күрсәтелгән сүзләрне географик исемнәр куеп укырга кирәк.

Ягез әле, укучылар, үзегезнең белемегезне сынап карагыз!

Касыйм Тимергалин,
Сарман урта мәктәбе укытучысы.

Омск шәһәре пионерлары өлкә пионерлар йортының энергетика түгәрәге членнары С. Ф. Горейко житәкчелегендә аэроконьки конструкцияләделәр. РӘСЕМДӘ: Володя Хаустов Омск шәһәре стадионында аэроконькида йөри.

К. Злодеев фотосы. (ТАСС фото-клишесе).

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

„ПИОНЕР КАЛЯМЕ“

ЕЖЕМЕСЯЧНЫЙ ЖУРНАЛ ПИОНЕРОВ И ШКОЛЬНИКОВ

ОРГАН ОБКОМА ВЛКСМ И НАРКОМПРОСА ТАССР.